# Образование
## Нижнекамского муниципального района

2024

# ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫК – УКУЧЫНЫҢ УҢЫШ НИГЕЗЕ

**Мифтахова Эльмира Флуровна,**
*14 нче лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Түбән Кама муниципаль районы*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары методик берләшмәсе җитәкчесе*



Укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү мәгариф системасында бүген актуаль проблема.

Функциональ грамоталылык – ул кешенең тышкы мөхит белән мөнәсәбәткә керү, тиз җайлашу һәм эзләү сәләте.

Функциональ яктан белемле шәхес – ул танып белүче, кеше арасында яши белүче, мөстәкыйль, заманча мәгълүмати технологияләргә ия кеше.

Укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштырып, без максатчан рәвештә белем бирү сыйфатын күтәрү, уку сыйфатын күтәрү өстендә эшлибез.

Татар теле һәм әдәдбияты дәресләрендә укучыларның функциональ грамоталыгын үстерү өстендә нинди эшләр алып барырга мөмкин? Алымнар күп, болар: инсерт, көндәлек, сюжет таблицасы, синтез-таблица, текст белән эш алымнары.

**Ә хәзер текст белән эш этапларын искә төшерсәк**

- укуга кадәр (чакыру чоры)
- уку вакыты (аңлау чоры)
- укудан соң (рефлексия чоры)

**Текст белән эшләү алгоритмы**

Текстны аңлау алымнары
- текстка сораулар кую
- текстны тезислар рәвешендә тәкъдим итү
- текстны график, схема рәвешендә тәкъдим итү
- план төзү
- аңлатмалы уку
- логик истә калдыру

- Укуга кадәр (чакыру чоры), бу этапта укучыларны йөгерек укуга әзерлибез (тиз уку күнекмәләрен үстерү күнегүләре, укыласы әсәргә кызыксыну уяту алымнары)

**1. Кушымча өстәп уку**

Кыш килде һәм урамнар... ак юрган җәйде. Рәшитнең әнисе... эше артты. Ул тротуар чистартырга урамга чыкты. Рәшит тә үзе кебек кечкенә көрәк алды да кар көри башлады. Көрәге аның фанердан эшләнгән – җиңел.

Тротуар... кешеләр йөреп тора, берәүләр – бу якка, икенчеләре теге якка баралар. Барысы да ашыгалар, кайберләре хәтта көрәк... дә басып узалар. Баштарак Рәшит алар... игътибар итмәде, эшендә булды. Менә бервакыт Рәшит көрәге... күтәрә алмады. Караса, бер бабай көрәге... баскан. Ул уйлап тормыйча: “Йөрмәгез әле эш вакыты... аяк астында чуалып!” – дип кычкырып җибәрде. Бабай бер генә сүз әйтте: “Ай-һай!” Әйтте дә китеп тә барды. Эш беткәч тә, ул сүз Рәшит... колак төбендә яңгырап торды. “Әни, нәрсә дигән сүз ул “ай-һай?” – дип сорады. Әнисе уйлап торды да болай диде: “Ай-һай”мы? Син, малай, эш яратасың икән - әйбәт! Әниеңә булушуың да матур! Тик олылар... тупас сүз әйтү әйбәт түгел дигән сүз ул “ай-һай”. (*Абдулла Әхмәттән*).

Син –табигать (бала). Табигать – (син) әйләнә-тирәң ул. Кояш, болыт, су, ком, таш, (хайван) һәм (үсемлек) – барысы бергә табигать дип атала. Кеше үзенә кирәк (әйбер) (табигать) (алырга). Иген, яшелчә һәм җиләк-җимешләр (үстерергә), терлек (үрчетергә).

(Җир асты) казылма байлыклар (чыгарырга). (Елгалар) һәм (күлләр) балык (тотарга). (Урман-кырлар) гөмбә һәм җиләк (җыярга).

Табигать бай, ләкин (ул) сакларга кирәк. (Табигать) (сакларга) – һәр (кеше) изге бурычы.

**2. Астан өскә уку**

**Җәйге каникулга кайткач, Гыйззәтуллиннның бер көне авыл белән танышып үтте.**

**Аларның авылында зур су юк. Электән суны көрәкләр белән буалар да, бала-чага, каз үрдәк шунда ята. Эссе көнне су җылы була, кояшны аз гына болыт капласа суына. 5) Җәй бик коры килгәндә, ул су кибә.**

**Шуңа күрә каз-үрдәк авызын ачып әлсерәп, тавышлары бетеп тилмереп йөри.**

**Инеш суы кипкәч, халыкның табигате бозыла, кеше үзеннән-үзе холыксызлана. 8) Ул кеше моның сәбәбен белми, әмма Гыйззәтуллин бик яхшы аңлый: сусызлык хикмәте бу. 9) Училищеда укый башлагач, Гыйззәтуллин үзенең күзәтүләрен тагын да тирәнәйтте. 10) Бигрәк тә психология фәнен өйрәнгәннән соң.**

**Халыкның мораль сыйфатлары, Гыйззәтуллин фикеренчә, әнә шуңа бәйле. Ул хәзер белә: зур сулы авылның халкы әйбәтрәк холыклы була.**


**Вакчыл булмый, киң күңелле, байлык туплау өчен артык көчәнми, әмма хөр тормышны ярата. Сусыз авыл халкы, киресенчә, вак холыклы һәм гайбәтчән була.**

**Өзлекле уку**

**Чишмәле, инешле авылның да эш ярыйсы. Болар эштә бик актив, боларның каралты-кура таза, холык-фигыль уртача. Чишмәле авылның тагын бер ягы бар: чишмә тавышын ишетеп үскән бала моңлы була. Мәсәлән, Гыйззәтуллин үзе җырлый белми, әмма күңеле тулы моң, йөрәгендә һәрвакыт җыр яши. Күңеле гел шуны җырлый. Моның сәбәбе - аларның авылы урманга якын. Ике чакрым үтсәң, урман. Чишмә буенда уйнап үскән кешенең яшьлеге урман белән бәйле.** (Мөхәммәт Мәһдиевтән)

**Катнаш уку**

**Астр@огия нилә@ сөй@и?**



Кы@ көне ту@ан бала@ Укчы, Кәҗәмөгез, Сукояр йолды@лыгы@ керәләр. Әлеге ел фа@ылын@ туган ке@е@ тор@ыш@, хе@мә@не яратып, у@ышлары@ сөенеп яш@. С@быр, бик акы@ы һәм бе@емле булу белән ае@ылып то@а@. Үс@әч, ях@ы җитәкче, инженер, г@лим, икъти@адчы, укы@учы, архе@лог б@лырга мөмкин@.

Көз көне туган бала... Кыз, Ү...чәү, Чаян йолдызл..гына ту..ы килә... Алар - нык ха...актер..., шат күңелле, кешелекле кешеләр. Белемгә омтылулары чиксез. Кешеләр арасында ихтирам казаналар. Үскәч, адвокат, дипломат, журналист, артист, җитәкче, хирург булырга мөмкиннәр.

Җәй көне туган балалар Игезәкләр, Кысла, Арыслан йолдызлыгына туры киләләр. Алар акыллы, сөйкемле, бөтен нәрсә белән кызыксына, киң күңелле, шәфкать-леләр. Алар - шәп дус, иптәш, ярдәмчеләр. Үскәч, яхшы җитәкче, галим, музыкант булырга мөмкиннәр.

Яз көне туган балалар Балык, Кучкар, Үгезбозау йолдызлыгына туры киләләр. Алар башлы, хәтерле, белемгә сәләтле, сәнгатьне яраталар. Үскәч, шәп рәссам, сынчы-скульптор, музыкант, табиб, талантлы гаскәр башлыгы, журналист, тегүче, пешекче булырга мөмкиннәр.

“Укый белү – ул хәрефләрдән тирән мәгънәне таба алу” дип яза К.Д. Ушинский. Шуңа күрә уку дәресләренең төп бурычы - укучыларда йөгерек, аңлы, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, текст һәм китап белән эшләү осталыгы тәрбияләү.

6с, 7с, 8с, 9с. Хәзер бу технологияне без Татар халык әкияте “Өч кыз” һәм А. Алишның “Килделәр” хикәясе мисалында карап үтәрбез. Тестны укуга әзерлек этабын проблемалы ситуция чишүдән башлыйбыз. Рәсемнәр буенча берничә күнегү эшлибез.

Кошлар килде

Кунаклар килде

Хат килде

Фашист килде.

Һәр ситуацияне уйнап күрсәтәләр.

Мәсәлән “Фашист килде” темасына балалар үз кичерешләрен язалар. Шушы эшләрдән соң текстны уку башлана. Текст укытучы тарафыннан укыла яки аудиозапись тыңланыла. Аннан соң геройларны билгеләү, әкиятләр булган очракта символны табу, сюжет - план төзү, өлешләргә бүлү башкарыла. Әкияткә, хикәягә модель төзелә. Әкият, хикәянең бер өлешен уйнап күрсәтү.

***“Туктап уку “*** алымы үз эченә түбәндәге этапларны ала.

• Текстның исеменә яки текстка бирелгән рәсемгә карап, текстның темасын, эчтәлеген ачыклау.

• Текстны уку барышында туктап “Алга таба текстта нинди күренешләр көтелә. Ни өчен алай уйлыйсыз?” кебек сораулар куела.

• *Өченче этап.* Йомгаклау әңгәмәсе. Бу этапта балалар белән фикер алышу, эзләнү, бүлеккә исем кую, текстка туры килгән мәкальләр уйлау, иҗади эшләр керә. Бу алым балаларны текстка анализ ясарга, автор позициясен, үз позициясен дөрес итеп аңлата белергә өйрәтә.

***3. “Эзләнеп уку” т***екстган кирәкле информацияне таба белергә өйрәтә. Әсәрдән нindидер вакыйганы, күренешне,текстның төп мәгънәсен аңлаткан җөмләне, текстган, бирелгән рәсемгә туры килгән өлешне табып уку; рольләргә бүлеп укырга мөмкин булган өлешне табып уку кебек биремнәр тәкъдим ителә.

1. “***Терәк сүзләр” алымы.*** Укытучы балаларга тема буенча терәк сүзләр тәкъдим итә. Балалар, алдагы белемнәренә таянып, бирелгән сүзләрне кулланып җөмлә яки мини-текст төзиләр һәм дәреснең темасын, максатын ачыклыйлар.( Бу алым дәрестә проблемалы ситуацияләр тудыру өчен дә уңайлы.)

Мәсәлән, Константин Ушинскийның “Дүрт теләк” хикәясен өйрәнгәндә, түбәндәге терәк сүзләр бирелә: ***кыш, яз, җәй, көз;***

• балалар, булган белемнәренә таянып, бу сүзләрне кертеп җөмләләр яки мини-текст төзиләр.

• дәреснең темасын һәм максатларын ачыклыйлар, түбәндәге җавапларны ишетергә мөмкин:

- текстта ел фасыллары турында укырбыз;
- һәр ел фасылының билгеләрен ныгытырбыз;
- һәр ел фасылының матурлыгын күрә, тоя белергә өйрәнербез;

***Текст эчтәлеген геройлар исеменнән сөйләтү***. Балалар үзләрен геройролендә хис итәләр. Рәисә Ишморатованың ”Яңа чана” хикәясендә укучы “Әтисе Раиләгә яңа чана алып кайтты” җөмләсен “Әти миңа яңа чана алып кайтты....” дип 1 зат исеменнән сөйли.

**«Инсерт» - заметки на полях**

**Сюжет таблицасы**

**Синтез – таблица**

**«Көндәлек”**

Озын сүзнең кыскасы шул, эшләр өчен мөмкинлекләребеә дә, технологияләр дә , алымнар да күп. Шуларны кулланып һәр яңа дәресебез яңа иҗат җимешебез дип әйтер идем мин. Без, укытучылар, барыбыз да иҗат итәбез. Баланың ак кәгазьдәй саф күңеленә ак нур белән эзләр салабыз. Шул эзләрнең якты, мәгънәле булуы өчен гомеребез буена тырышырга, эзләнергә тиешбез.

Укучыларга әсәр эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр тәкъдим итәм.Алар әсәр эчтәлегенә бәйле рәвештә бирелгән рәсемнәр буенча вакыйгаларны әйтә белергә тиешләр.Мәсәлән:





1. Кыш җитте,тик менә Мирбат абый гына ни хәл итсен,һаман да шул ямаулы башы белән йөрүен дәвам итте.Теге цирктагы клоун төсле кызыллы – яшелле бүркен киеп.



15


4. ***Автор кипкән ботак белән кемне чагыштыра?***

“Бу кипкән ботак миннән дөнья бәясе каерачак.10 ел эзләдем бит мин бу бүрекне”,- дип уйлады Мирбат абый.” Син 10 ел эзләсәң,мин 15 ел сата алмый изаланган идем бу бүрекне”,-диде сатучы.Икесе дә риза булып куллар кысышты.

“**Лото**” уены отышлы. Укучыларга уен башланыр алдыннан әзер таблицалар таратыла.Аларга күренекле шәхесләрнең исемнәре язылган.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Муса Җәлил | Кәрим Тинчурин | Рөстәм Яхин | Шәүкәт Галиев |
| Хәсән Туфан | Әмирхан Еники | Туфан Миңнуллин | Байназар Әлминов |
| Фатих Әмирхан | Кәнәфи Нәфыйков | Гаяз Исхакый | Нәби Дәүли |
| Хаҗиморат Козаков | Сәлих Сәйдәшев | Абдулла Алиш | Габдулла Тукай |

Укучылар сорауга туры килгән җавапны сыза баралар. Ахырдан 2 яки 1 фамилия генә калырга мөмкин. Ул дәрестә өйрәнеләчәк язучы да булырга мөмкин.

1. Бөек Ватан сугышы чоры язучыларын табып сызыгыз.
2. Татар рәссамнарын табыгыз.
3. Татар композиторларын уеннан чыгарыгыз.
4. Шагыйрьләрне билгеләгез.
5. Татар театры үсешенә зур өлеш керткән драматургларны табыгыз.

Калган фамилия – сезнең җавабыгыз.

Яисә, гади генә менә шундый ысулны да кулланырга мөмкин. Укучыларга тема буенча төрле картиналар тәкъдим итәм.





Иң элек шундый сорау тәкъдим итәм :"Әлеге рәсемнәрне нәрсә берләштерә? Укучылар бу шигырьләрнең авторы Муса Җәлил булуын әйтергә,шигырьләренең исемнәрен атарга тиешләр. Дүртенче рәсемне күрсәтеп "Бүген нинди шигыре белән танышырбыз?" дигән сорау белән рәсем буенча фикер алышу үткәрәм.(М.Җәлил "Серле йомгак").

## ТУГАН ТЕЛЛӘР УКЫТУНЫҢ АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ.

***Исмәгыйлова Алина Альбин кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама»*
*полилингваль гимназиясе укыту эшләре буенча*
*директор урынбасары*



«Адымнар – Түбән Кама» күптелле гимназиясендә «Туган телләр укытуның актуаль проблемалары» исемлетөбәкара фәнни-методик семинарныүткәрү матур традициягә әверелде.

Семинар үткәрүнең максаты - белем бирү дәрәҗәләре арасындагы эзлеклелекне исәпкә алып, туган телләрне өйрәтү процессын оештыру буенча дөньякүләм һәм Россия тәҗрибәсе белән танышу, киләчәккә эш перспективаларын билгеләү, туган телләр үсешен укыту-методик тәэмин итүнең уңай тәҗрибәләрен тарату, туган телләрне саклап калуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларның актуальлеген тикшерү, Татарстан Республикасы халыкларының рухи мирасына кыйммәтле мөнәсәбәт формалаштыру.

Чарадагадәттәгечә Татарстан һәм Башкортстан Республикаларыннан 200 дән артык кеше катнаша.

Семинарның төп темалары:

- туган телгә һәм әдәбиятка өйрәтүнең нәтиҗәле ысуллары;
- гомуми белем бирү оешмасында туган телгә өйрәтү проблемасы һәм технологияләре;
- туган телләрне саклау һәм үстерү буенча иң яхшы тәҗрибәләрне презентацияләү.

«Адымнар - Түбән Кама» гимназиясе укытучылары татар һәм инглиз телләрендә интеграль дәрес, математика, татар теле, тарих һәм әйләнә-тирә дөнья дәресләрен күрсәтәләр. Шулай ук анимация, блогерлык, театр, журналистика, шахмат, рус теле буенча мастер-класслар уза.




Пленар утырышта семинарда катнашучылар сорауларга җавап бирәләр, дискуссияләрдә катнашалар, үз тәҗрибәләре белән уртаклашалар.

***Сергеева Гөлназ Сөнгатулла кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама»*
*полилингваль гимназиясе башлангыч сыйныф укытучысы*



**Предмет:** Татар теле дәресе, 4 сыйныф
**Тема:** «Санлы сандык»
**Максат:**1. Сан турында мәгълүмат булдыру, саннарны сөйләмдә дөрес куллану күнекмәләре булдыру;
3. Туган телдә аралашуга омтылыш тәрбияләү
2. Санны сөйләмдә куллану күнекмәләрен камилләштерү, укучыларның

| | | |
|---|---|---|
| **Көтелгән нәтиҗә:** | Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре | Укытучы укыганны һәм сөйләгәнне игътибар белән тыңлый белә; |
| | Регулятив универсаль уку гамәлләре | күнегүләрне бирелгән үрнәк һәм кагыйдә буенча планлаштыра ала, тикшерә, башкара; |
| | Танып-белү универсаль уку гамәлләре | ничә?, күпме?, никадәр?, ničәнче? соравына җавап булган сүзләрне аера һәм таный; сан сүз төркеме дип аңлый; санны сөйләмдә куллана ала; |
| | Коммуникатив универсаль уку гамәлләре | укучыларның сүзлек хәзинәсе арта, үз фикерләрен төгәл һәм ачык итеп белдерә алалар, кара-каршы әдәпле сөйләшә һәм кеше хезмәтенә хөрмәт уяна. |
| **Төп билгеләр** | Сан, саннарны сөйләмдә дөрес куллану | |
| **Предметара бәйләнеш** | математика | |
| **Чыганаклар** | Дәреслек: Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова. Татар теле. 4 класс. Мөстәкыйль эш өчен биремнәр. Эш дәфтәрләре. | |
| **Җиһазлау** | Компьютер, карточкалар, презентация, көзге белән тартма. | |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, парларда, төркемнәрдә сөйләм телен үстерү; | |

**1 этап.Оештыру өлеше. Дәрескә уңай атмосфера, кызыксыну тудыру.**

- Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн кунаклар! Кәефләрегез ничек?

(Ал да гөл хәй, ал да гөл хәй,
Монда рәхәт, шуны бел хәй)

“Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр,” - диләр. Бер-беребезгә карап елмаябыз, бер-беребезне сәламлибез. Янныбыздагы күршебезгә “биш”не бирәбез, “син бүген шундый матур” диябез. “Яхшы уңышлар сиңа телим” диеп, дәресне башлап җибәрәбез. Парталарда төсле тасмалар ята. Үзегезгә бер төсне сайлагыз, бэйджикларга беркетегез. Сезнең һәрберегезгә бу сайланган төс яңа белемнәрне үзләштерү өчен зур уңыш китерсен.

**2 этап. Актуальләштерү. Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру.**

Иң элек дәрескә булган кагыйдәләрне искә төшереп үтәсем килә. (Һәр кагыйдә укыла һәм магнитлы тактага эленеп куела).

Әдәпле һәм игътибарлы бул!
Сүзеңне ачык һәм дөрес әйт!
Иптәшләреңне хөрмәт ит!
Башкаларны бүлдермә!

Нәрсә турында сөйләшербез микән бүген? Моны без ребусны чишкәч, белербез. Карагыз әле тактага, монда нинди сүз качып ята икән?

- Нинди сүз килеп чыкты? (“Сан” сүзе).

**3 этап. Уку мәсьәләсен кую.**

Димәк, укучылар, без бүген сезнең белән ......**саннар** турында сөйләшүне дәвам итәбез, сан турында белемнәребезне тагын да тирәнәйтербез.

Әйтегез әле, саннарны тормышта кайларда кулланабыз? (сәгать, математика дәресендә, кибеттә, еллар, айлар, көннәр санала.....)

**4 этап. Танып-белү эшчәнлеге. Уку мәсьәләсен чишү.**

Саннарны беләсезме икән? Тикшереп карыйк әле! Сезгә әлеге биремдә саннарны сүзләр белән алыштырырга кирәк булачак.

(Раунд Тэйбл структурасы). Төркемегездә иң озын буйлы укучы башлый.

- Тикшерәбез, Әфәрин!

- Укучылар, бу сүзләрне төркемнәргә бүлеп була микән? Аларның язылышына игътибар итегез әле.

Ясалышы ягыннан **гади саннар**, **кушма саннар** һәм **тезмә саннар** була.

**Гади саннар -** бер сүздән генә, ягъни бер тамырдан гына торган саннар.

**Кушма саннар** ике сүз, ягъни ике тамыр бергә кушылып ясалган саннар. Кушма саннар кушылып язылалар. Кечкенә генә сер сезгә ачам. Кушма саннар тугыз гына. Унбердән алып унтугызга кадәрге саннар кушма саннар булалар.

**Тезмә саннар** ике яки берничә сүз тезелеп килгән саннар. Тезмә саннар аерым язылалар.

| **Гади саннар** | **Кушма саннар** | **Тезмә саннар** |
|---|---|---|
| Ике | унбер | егерме алты |
| Җиде | унике | илле дүрт |

*Ә сез мисал китерә алырсыз микән? Такта янына.....Кызлардан гына торган төркем чыга.*

<u>Динамик пауза</u>

**Микс-фриз-груп** структурасы.

Музыкага бииләр, кушылалар. Музыка туктагач басып катып калалар. Сорау бирелә.Бер кеше дә җавапны кычкырып әйтми, ә эченнән генә уйлый. Шул сан белән төркем барлыкка килә.

- Елның *ничә* фасылын беләсез? (4 фасылы)

10нан алам 5не (биш)

- Бүген атнаның *ничәнче көне*? (2 көне)

-16ны бүләм 4кә (дүрт)

- Бер атнада ничә көн? (7 көн)

- Кышның *ничә ае* бар? (3 ае)

- Хәзер сыйныфта *ничә укучы*? (16)

- Менә шулай бердәм булып дәресебезне дәвам итәбез.

- Рәхмәт. Иптәшебезгә рәхмәт әйтик. Син шундый акыллы, воооо!

- Бейджикларыгызны карагыз. Дәрес башында сезнең һәрберегез уңышка төс сайлады. Төсләр буенча җыелып яңа команда төзегез. Яңа урыннарга үтегез.

<u>**5 этап. Яңа белемнәрне ныгыту.**</u>

Карточкаларга язып эшлиләр. Һәркем үзе.

Елда .... ай. Бер айда .... атна. Атнада ... көн. Бер тәүлектә ... сәгать. Бер сәгатьтә ... минут, ә бер минутта ... секунд. (Парларда тикшерү).

- Алда сезне яңа уен көтә. Ул уенның исеме “Сүздәге хәрефне алыштыр, һәм яңа сан китереп чыгар”.

<u>**6 этап. Яңа белемнәрне мөстәкыйль куллану һәм тикшерү (группада эш)**</u>

Саннарның язылышына бәйле хаталы очракларны табарга. Хаталы язылган сүзләрнең астына сызарга һәм дөрес язылышын аңлатырга.

1. Ун икеай сизелми дә үтеп китте.
2. Әниемә утызалты яшь.
3. Егермеөченче февраль – Ватанны саклаучылар көне.
4. Ике гасырда икейөз ел.
5. Сигез елдан миңа унсигез тула.

<u>**7 этап. Уку эшчәнлеген йомгаклау.**</u>

Рефлексия.

- Бу дәрестә син нәрсә белдең?

- Син нәрсә эшләргә өйрәндең?

- Модель буенча бүген белгәннәреңне яныңдагы иптәшеңә сөйләп чык.

- Сан турында нәрсә кабатларга яки белергә теләр идегез? Бу сорауга стикерларга языгыз һәм парковка урынына ябыштырыгыз, бу сезнең дәрестән чыгу билетыгыз булачак.

<u>**8 этап. Өй эше.**</u>

Иҗади эш.

1) Ике саны кергән мәкальләр язарга.

2) Синквейн тозергә.

- Бер-берегезгә матур сүзләр, рәхмәт әйтегез дә минем яныма килегез.Монда бер сихри тартма бар, аның эчендә бугенге дәрестә сез иң сәләтле, иң актив укучының сурәтен күрерсез. (көзге)

***Сергеева Гөлназ Сөнгатулла кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль*
*гимназиясе башлангыч сыйныф укытучысы*
***Мөхәммәдҗанова Гөлшат Илдус кызы,***
*94 нче «Сөенеч» балалар бакчасытатарһәм рус телләрен укыту*
*буенча тәрбияче*





**Предмет:** «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтүдә уен формалары»

**Тема:** «Коткаручыларның маҗаралары»

**Бурычлар:**

1. Балаларның коммуникатив сыйфатларын үстерү, диалогик сөйләмне камилләштерү.


2. Балаларга дус мөнәсәбәт, ярдәмләшәсе килү теләген тәрбияләү.


3. Балаларда артистлык сыйфатлары тәрбияләү, театральләштерелгән тамашалар аша иҗади потенциалларын ачу. Күңелле, тойгылы халәт тудыру.


| | | |
|---|---|---|
| **Көтелгән нәтиҗә:** | шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре | балалар сөйләгәнне игътибар белән тыңлый белә; |
| | регулятив универсаль уку гамәлләре | биремнәрне башкара; |
| | танып-белү универсаль уку гамәлләре | нәрсә? нинди? кайда? соравына җавап булган сүзләрне аера һәм таный, сөйләмдә куллана ала; |
| | коммуникатив универсаль уку гамәлләре | укучыларның сүзлек хәзинәсе арта, үз фикерләрен төгәл һәм ачык итеп белдерә алалар, кара-каршы әдәпле сөйләшә. |
| **Предметара бәйләнеш** | Әйләнә-тирә | |
| **Җиһазлау** | Компьютер, презентация, агач, өй, алан макетлары. Яшелчә, җиләк – җимеш муляжлары. | |
| **Эшне оештыру** | Фронталь | |

**Шөгыль барышы**

Балалар кереп бер рәткә тезелеп басалар. Алып баручы каршыларына баса.

| | |
|---|---|
| | **Алып бар.:-** Исәнмесез, балалар. Хәлләр ничек? |
|     | *Ватсап тавышы куела.*<br>- Балалар, ватсабыма кемдер шалтырата.<br>*“Аю һәм Маша” әкиятеннән Маша пәйда була.*<br>- Исәнмесез, балалар. Мине таныгансыздыр. Мин Маша. Мин урманда йөргәндә, Аю өенә ял итәргә кердем, ә ул мине хәзер җибәрми. Дусларым, монда килеп мине коткарыгызчы. Юлны исегездә калдырыгыз. Башта басу буйлап, аннары урман буйлап барасы, урманда Аю өен табырсыз. Мин көтәм сезне, дусларым.<br>**Алып бар.:-** Балалар, булышабызмы? *(әйе)* Без бүген чын коткаручылар ролендә булабыз икән.<br>- Кем хәтерли, нинди юл буйлап барасы? Башта кая барасы? Әйе, басу буйлап. *(Тактага басу рәсеме куела)*<br>- Барганда, күңелле булсын өчен җырлап барыйк.<br>*Барабыз, барабыз,*<br>*Машаны коткарабыз.*<br>*СМС тавышы куела.*<br>- Балалар, минем телефоныма смс килде. “Исәнмесез, балалар. Мин кечкенә куян. Мин яшелчә, җиләк-җимеш белән кәрзинемне тотып барган идем. Ләкин кинәт кенә төлке килеп чыгып, мине куркытты. Һәм мин кәрзинемне ташлап бөтен көчемә йөгереп качтым. Мин һаман да куак астында куркып утырам. Әгәр |

| | |
|---|---|
|  | дә минем кәрзинемне тапсагыз, үзегез белән алыгыз зинһар.”<br>- Ярый, тапсак, үзебез белән алырбыз. Киттек алга таба.<br>*Барабыз, барабыз,*<br>*Машаны коткарабыз.*<br>*(Тактага урман рәсеме куела)* |
|  | **Алып бар.:**- Карагыз әле, менә бит куянның кәрзине табылган. Командаларга бүленеп аерым яшелчәләрне, аерым җиләк-җимешләрне җыйыйк әле.<br>*(Музыкага кушылып җыялар).*<br>- Кәрзиндә нәрсә бар? *(кәбестә,кишер, бәрәңге, кыяр, суган)* Ничә? (10) Икенче кәрзиндә нәрсә бар? *(алма, виноград, персик, лимон, апельсин)* Ничә? (10)Куян үзе күренгәч бирербез әле. |
| <br> | - Юлыбызны дәвам итәбез.<br>*Барабыз, барабыз,*<br>*Машаны коткарабыз,*<br>*Куаклардан куркынып кына куян чыга.*<br>**Алып бар.:**- Исәнме, куян.<br>- Исәнмесез. Төлкене күрмәдегезме?<br>**Алып бар.:**- Юк. Без синең смс алдык. Һәм югалткан ашамлыкларны җыеп алдык.Ашыйсың киләме?<br>- Әйе. Рәхмәт.<br>**Алып бар.:**- Балалар хәзер сине сыйлаячак. Куян нәрсә ашый?*(кәбестә, кишер, алма)*. Алина,куянны сыйла. *(Куян, мә кишер аша. Кишер тәмле, чиста, зур, баллы)* Вика, сыйла. (*Куян, мә кәбестә аша. Кәбестә тәмле, чиста, зур,яшел)*<br>- *(Куян ала, ашаган була)* Рәхмәт. Бик тәмле икән.<br>**Алып бар.:**- Куян, ашап туйдыңмы?<br>- Әйе.<br>**Алып бар.:**Куян, син курыкмыйча өеңә кайт инде. Ә без балалар белән Аю өенә барып Машаны коткарабыз. Аның өе кайдарак икән?<br>- Әәнә тегендә *(кулы белән күрсәтә),* ерак калмады сезгә.<br>**Алып бар.:**- Сау булыгыз.<br>- Сау булыгыз.*(Куян китә)* |
| <br>Үзе бер дә ашамый,<br>ашаганда бушамый<br><br>Өй эчендә<br>түгәрәк күл<br> | **Алып бар.:**- Балалар, кая барабыз? *(Аю өенә)*<br>Җырлап барыйк.<br>*Барабыз, барабыз,*<br>*Машаны коткарабыз,*<br>*Интерактив тактада аю өенең рәсеме.*<br>*Без Аю өенә шакыйбыз.*<br>**Аю:***(ачулы тавыш белән)*- Кем анда? Нишләп йөрисез?<br>**Алып бар.:***(баларга карап)*- Күрәсезме, Аю бик ачулы, усал күренә. Нигә микән? Бәлки, аңа берүзенә күңелсездер? Бәлки аның дуслары юктыр? Әгәр без аның белән дуслашсак, бәлки аның йөзе яктырыр? Исәнмесез, Аю<br>**Аю: -** Исәнмесез.<br>**Алып бар.:**-Без Машаны коткарырга килдек.<br>**Аю: -** Минем аны җибәрәсе килми. Миңа аның белән бик күңелле.<br>**Алып бар.:**- Көчләп кешене тотарга ярамый бит, көчләп кеше белән дус булмассың.<br>**Аю:**- Анысы шулай да бит. Әйдәгез, болай итик. Минем биремнәрне үтәсәгез, Машаны сезнең белән җибәрермен.<br>**Аю. -** Беренче бирем. Табышмакларга җавап бирегез.<br>*Тактада сүзләре чыга.*<br>**Аю. -** Үзе бер дә ашамый, ашаганда бушамый *(кашык)* |
| | **Аю. -** Өй эчендә түгәрәк күл *(тәлинкә)* |

| | |
|---|---|
|  | **Аю. -** Үзе жырлый, үзе сыйлый *(Самовар)*<br>- Ә самовардан нәрсә эчәләр? Чәй. Нәрсәгә салып? Чынаякка.<br>**Аю:-** Дөрес җавап бирдегез. Икенче биремем. Чынаяк дип әйттегез бит, шуның турында берәр күңелле җыр җырлагызчы. Менә нинди авыр эш куштым. *(көлә)*<br>**Алып бар.:-** Ярый, без бик күңелле җыр беләбез, "Зәңгәр чынаяк" дип атала. *(җырлыйбыз)* |
| | **Аю:-** Бик матур җырладыгыз, рәхмәт. Өченче биремне дә тыңлагыз инде. Шуны эшләсәгез, Маша сезнеке.<br>*Интерактив тактада бирем.*<br>**Аю:-** Минем дусларымны танысыйсызмы? Нинди әкияттән алар? *(Өч аю)* |
|  | **Аю: -** Бу дустым Михайло Потапыч. Бу Настасья Петровна, ә бу Мишутка. Биремем шундый: һәрберсе астында размерына карап предметларны куегыз. *(караватъ, урындык,өстәл)*<br>**Алып бар.:-** Михайло Потапычның предметлары нинди? (зур) Настасья Петровнаның предметлары нинди? *(уртача зурлыкта)* Мишутканыкы нинди? (*кечкенә)*<br>**Аю: -** Афәрин, булдырдыгыз. Ну Маша сине дусларың белән җибәрергә туры килер*(авыр сулап куя)* |
|  | **Алып бар.:-** Аю, син бик борчылма инде. Безгә балалар бакчасына кунакка килерсең. Балалар, Аюны бергәләп чакырыйк әле.<br>*- Аю, безгә кунакка кил.*<br>*- Без сине көтәрбез.*<br>*- Сине күрергә бик шат булырбыз.*<br>**Аю:-** Рәхмәт. Алай каты чакыргач килермен.<br>**Маша:-** Син бер дә усал түгелсең икән. *(Аюны кочаклый)*<br>**Аю:-** Тиздән кунакка килермен.<br>**Алып бар.:-** Сау бул, Аю.<br>**Алып бар.:-** Бүген без сезнең белән чын коткаручылар ролендә булдык. Маша, син башка урманга берүзең генә йөрмә. Машага да өенә кайтырга кирәк. Әти-әниең борчыла торганнардыр.<br>**Алып бар.:-** Бүгенге күңелле сәяхәтебез турында кайтып әти-әниләрегезгә сөйләрсез. Сау булыгыз, балалар.<br>**Алып бар.:-** Ә без балалар бакчасына кайтыйк. Маша, сине эзләгән вакытында без шигырь сөйләп бардык. Син дә тыңла әле.<br>Машаны эзләп таптык,<br>Машаны без коткардык.<br>*(Сөйләгән арада интерактив тактада балалар бакчасы рәсеме куела.)* |

**Зәйдуллина Энҗе Фәиз кызы,**
*«Адымнар – Түбән Кама»*
*полилингваль гимназиясе туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Хатыйпова Евгения Александр кызы***
*«Адымнар – Түбән Кама»*
*полилингваль гимназиясе инглиз теле укытучы*



**Предмет:** Татар теле һәм технология буенча интеграль дәресе, 5 сыйныф.

**Тема:** «Татар халык ашлары» – «Tatar national cuisine»

**Максат:** Татар халкының гореф - гадәтләрен хөрмәтләргә өйрәтү, милли ризыкларына кызыксыну уяту, толерант шәхес тәрбияләү.

| | | |
|---|---|---|
| **Бурычлары:** | белем бирү | укучының әдәби тел нормаларын саклап иркен сөйләшүенә һәм фикер алышуына ирешү |

| | | |
|---|---|---|
| | белемнәрне ныгыту һәм камилләштерү | сүзлек запасларын баету, татар халык ашларының атамаларын сөйләмдә камилләштерү |
| | тәрбияви | пешекче хезмәтенә хөрмәт белән карау; төгәллек, игътибарлылык, мөстәкыйльлек, пөхтәлек сыйфатлары булдыру; үз хезмәтеңнең нәтиҗәсен күреп, горурлану хисе тудыру. |
| **Предметара бәйләнеш** | татар теле, инглиз теле, хезмәт. | |
| **Чыганаклар** | Р.Р. Шәмсетдинова, Г.К.Һадиева, Г.В.Һадиева, “Татар теле” 5 нче сыйныф өчен дәреслек, Казан “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2020. | |
| **Җиһазлау** | Компьютер, карточкалар, презентация, күзгә белән тартма. | |
| **Эшне оештыру** | компьютер, проектор, экран, тема буенча таратма материаллар, карточкалар, презентация, видео, аудиоязма, буклетлар, рәсемнәр, өчпочмак өчен кирәк булган продуктлар | |

## Дәрес барышы

| Дәрес этаплары | Дәрес этабының максаты | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|---|
| **I. Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.** | **Укытучы өчен максат:** психологик уңай халәт барлыкка китерү. Төркемнәрнең дәрескә хәзерлеген күзәтү, барлау; белем алырга әзерлек алып бару. | Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.<br>- Исәнмесез, укучылар! Хәерле көннәр!<br>- Good morning, dear students!<br>- Let’s begin today’s lesson.<br>-Кәефләр ничек?<br>-How are you?<br>-Балалар, сез әзерме?<br>-Яхшы кәеф, уңышлар теләп дәресебезне башлап җибәрик. | - Исәнмесез!<br><br>- Шәп. Алда гөл, хәй! Алда гөл, хәй, монда рәхәт, шуны бел, хәй!<br>Алда гөл, хәй! Алда гөл, хәй, монда рәхәт, шуны бел, хәй!<br>-Әзер, әзер, әзер, әзер! | <u>Коммуникатив:</u> классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү<br><u>Шәхси:</u> үзмаксат кую<br><u>Регулятив:</u> дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү |
| **II. Белемнәрне актуальләштерү.** | | -Игътибарыбызны экранга юнәлтик әле.<br>-Look at the screen please! (Салават һәм Гүзәлемнең ”Милли ашлар” җырыннан өзек). | Җырдан өзек карау. | **Шәхси:** татар халык ашларының исемнәрен әйтергә теләк тудыру. |
| **III. Уку мәсьәләсен кую** | **Укытучы өчен максат:** яңа белемнәр кабул итүне оештыру һәм үзләштерүгә юнәлеш бирү<br>**Укучылар өчен максат**: килеп туган уку мәсьәләсен анализлау; дәреснең темасын, максатын билгели белү | -Сез нинди татар халык ашларын күрдегез?<br>- Бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләшербез?<br>-What will we discuss today?<br>- Әйе, бүген без сезнең белән татар халык ашлары турында сөйләшербез.<br>-We will discuss Tatar national cuisine today!<br>-2 төркемгә бүленербез. Һәр дөрес җавап өчен баллар бирелә һәм дәрес ахырында нәтиҗә ясарбыз. 1.табышмак лампа (слайд)<br>-Ничек уйлыйсыз, бу татар халкының нинди милли ризыгы?<br>- Димәк, без бүгенге дәресебездә сезнең белән | -Өчпочмак, гөбәдия, чәкчәк.<br><br><br><br>-Tatar national cuisine. | <u>Танып-белү</u>: танып белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм максат кую<br><u>Регулятив</u>: эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;<br><u>Коммуникатив</u>: коллектив эшләүдә катнашу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | бергәләп, өчпочмакларны ясарга өйрәнербез. Ә аны пешерү өчен нәрсәләр кирәк булачак? (тактада язылган +слайд) | -Өчпочмак. | |
| **IV.Уку мәсьәләсен адымлап чишү.** | **Укытучы өчен максат**: Таныш белемнәргә таянып, уку мәсьәләсен адымлап чишү. **Укучылар өчен максат:** Яңа лексик материалны таныш конструкцияләрдә куллану | ***1. Эчлек өчен***: бәрәңге, ит, суган, борыч, май, тоз. ***Filling:*** potato, meat, onion, pepper , butter, salt (слайд) 2. **Бирем.** Һәр командадан 2 кеше чыга. Сүзләрне тоташтыралар. 2 pupils come to the blackboard to connect Tatar and English variants. 3. Өчпочмаклар турында кызык фактлар ( 4 сорау-видео).Discuss 4 interesting facts about our national dish (**“риза”** яки **“риза түгел”** табличкаларын күрсәтәләр). 1) Руссиядә иң зур өчпочмак 24 кг.The biggest өчпочмак weighs 24 kg. 2) Казанда өчпочмак һәйкәле бар. In Kazan you can find a monument to өчпочмак. 3) Макдоналдста мондый өчпомак алып була. You can buy очпочмак in McDonalds. 4) Футболка 10 000 доллар тора. The T-shirt costs 10 000 dollars. 4. Дәрестә куркынычсызлык кагыйдәләре (ТБ). Remember safety rules. 1.Put on an apron and a cook's cap. Баш киемнәрен һәм алъяпкычларны киегез.2. Wash your hands or use gloves. Кулларны юыгыз яки перчатка киегез. 3. Be careful using oven! Газ плитәсе янында сак булыгыз! 4. Don't forget to wash up and take the rubbish out Савыт-сабаны юарга, чүпләрне җыярга онытмагыз. Өчпочмак ясый башлыйлар(татар халык көе уйный). -Камырны кисәкләргә бүләбез, җәябез. We take a piece of dough and roll it. Туралган бәрәңгене, | Бәрәңге Potato<br>Ит Meat<br>Суган Onion<br>Май Butter<br>Тоз Salt<br><br>-Риза<br><br>-Риза<br><br>-Риза түгел.<br><br>-Риза түгел. | <u>Танып-белү</u>:уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру; аңлап әйтеп бирү; <u>Коммуникатив</u>: үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү <u>Регулятив:</u> үз эшчәнлегеңне контрольгә алу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | суганны, итне тоз белән бутыйбыз – бу өчпочмакның эчлеге була. We put the filling inside. Җәелгән камырның өстенә эчлекне салабыз да, өчпочмак формасын ясыйбыз. We make a form of triangle. Укытучы башта күрсәтә, аннары укучыларга ясарга булыша. We show the example to the pupils and then they begin cooking themselves. Өчпочмакларыбыз әзер, хәзер 40 минутка пешерергә куябыз. | Өчпочмак ясыйлар | |
| **V. Белемнәрне ныгыту** | **Укытучы өчен максат**: лексик материал сөйләмдә мөстәкыйль кулланылу дәрәҗәсенә җиткерү **Укучылар өчен максат:** белемнәрне диалогик сөйләмдә камилләштерү | 1. Диалогик сөйләм оештыру өчен, аралашу урынын билгеләү. Бирем: һәр командадан 1 укучы чыга һәм рәсемнәр, сүзләр ярдәмендә өчпочмак ясауны сөйли. 1нче команда татар телендә, 2 нче команда инглиз телендә. 1 person of each team will come th the blackboard to tell all the stages of our cooking in Tatar and English languages. | <u>1 команда:</u> өчпочмак пешерү өчен безнең эчлегебез әзер. Хәзер камыр кисәкләрен алабыз һәм аны җәябез. Эчлекне салабыз, өчпочмак формасы ясыйбыз. Өчпочмак әзер. <u>2 команда:</u> We take a piece of dough and roll it. We put the filling inside. We make a form of triangle. | <u>Шәхси:</u> күршеңә ярдәм итүдә танып белү инициативасы күрсәтү <u>Регулятив</u>: укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; <u>Танып-белү</u>: тиешле мәгълүматны сайлап алу <u>Коммуникатив:</u> Аралашу бурычлары нигезендә үзеңнең фикерләреңне тулы һәм төгәл итеп әйтеп бирә белү |
| **VI. Өй эше .** | **Укытучы өчен максат**: өй эшен хәбәр итү, аны башкару ысулын аңлату. **Укучылар өчен максат:** өй эшен дөрес башкару | Эш 3 дәрәҗәдә тәкъдим ителә: 1) карточкада бирелгән сүзләрне татар теленнән инглиз теленә тәрҗемә итәргә (һәркем эшләргә тиеш); 2) берәр татар ашын пешерү тәртибен язып килергә (ярым иҗади, бу бирем ихтыярый) 3) хикәя төзергә (өегездә берәр бәйрәм өстәлен әзерләү турында хикәя төзергә (иҗади эшчәнлеккә, бу эш ихтыярый). | Өйгә эш алу. | |
| **VII. Рефлексия. Уку эшчәнлеген йомгаклау.** | **Укытучы өчен максат**: дәрестәге эшчәнлекне анализлау, | - Укучылар, бүген алган белемнәрне кайда кулланып була? - Хәзер өчпочмак рәсемнәре өләшәбез, | Балаларның җаваплары. | <u>Шәхси</u>: үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау <u>Танып-белү</u>: |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белемнәрне бәяләү һәм киләчәккә алмашлыкларны дөрес куллану.<br>**Укучылар өчен максат**: үз фикереңне дәлилләү, дәрестә алган белемнәренең әһәмиятен аңлау, аларны киләчәктә куллана белү | һәрберегез 3 тәлинкәнең берсенә җавапларыгызны беркетәсез.<br>I тәлинкә –Барысын да аңладым<br>II тәлинкә – Яңалык алдым<br>III тәлинкә – Авыррак булды<br>-Дәресебез тәмам, сау булыгыз укучылар!<br>-Thank you for your attention. Goodbye! | -Сау булыгыз!<br>-Good bye!<br>Thank you for the lesson! | фикерләүдә логик чылбыр төзү<br>Регулятив**:** эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү<br>Коммуникатив:<br>әңгәмәдәш аралашу калыбын төзү |

**Алтынова Гөлнара Закир кызы,**
*«Адымнар – Түбән Кама»*
*полилингваль гимназиясе башлангыч сыйныф укытучысы*



**Предмет:** Татар теле дәресе, 2 сыйныф.

**Тема: «**А.Алиш «Тукмар белән Чукмар» әкиятенә анализ»

**Максат:**1. А.Алишның “Тукмар белән Чукмар” әкиятенең эчтәлеген ачу;

2. Сөйләм телен шомарту, фикерне аңлаешлы, күңелдәге хисне матур итеп әйтеп бирә белү; уку күнекмәләрен, фикерләү сәләтен үстерү; уңай һәм начар геройларны, яхшы һәм алама гадәтләрне таный һәм бәяли белергә,балаларны логик яктан эзлекле итеп уйларга, үзфикерләрен нигезләргә һәм исбатларга өйрәтү.

3. Укучыларда әкият аша дуслык, татулык хисе тәрбияләү; әкиятләр укуга кызыксынуны арттыру.

| | | |
|---|---|---|
| **Көтелгән нәтиҗә:** | Шәхси нәтиҗәләр: | активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл эшчәнлегенә өйрәнү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү. |
| | Метапредмет нәтиҗәләре Регулятив УУГ | максатка ирешү юлларын билгеләү; укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү. |
| | Танып-белү УУГ | тел белеме һәм табигать белеме фәннәренең бәйләнешен аңлау. |
| | Коммуникатив УУГ | үз эшен контрольдә тоту, иптәшләренә ярдәм итү. |
| | Предмет нәтиҗәләре | “Тукмар белән Чукмар”әкиятен анализлау; уку күнекмәләрен үстерү. |
| **Җиһазлау** | интерактив такта, карточкалар. | |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, парларда, төркемнәрдә | |

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру өлеше.**

**Укытучы:** Исәнмесез, кадерле укучыларым. Хәерле көн, балалар.

**II. Проблемалы ситуация тудыру.**

(*Ишек ачыла, этешә – төртешә ике кыз керә.)*

***1 кыз:*** Мин беренче керәм, кит әле.

***2 кыз:*** Кит әле, бармакны кыстың бит.

***1 кыз:*** Син минем аякка бастың. *(елый- елый укытучыга әләкләшәләр)*

***2кыз: Ә*** ул минем бармакны кысты.

**Укытучы:** Укучылар, нәрсә булды? Я, тынычланыгыз әле.

**Укытучы:** Укучылар, бик ямьсез күренеш булды бит әле бу. Әйдәгез, кызлар, бер – берегездән гафу үтенегез дә, тыныч кына утырыгыз.

***1 кыз:*** Мин гаепле түгел. Ул гафу үтенсен.

**2*кыз:*** Син үзең гаепле.

**Укытучы:** Балалар  тынычландык.

**Укытучы:** Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, кызлар ишектән дөрес керделәрме? Алар нинди хаталар җибәрделәр.

***Укучылар:*** *Исәнләшмәделәр, керергә рөхсәт сорамадылар, әләкләштеләр...*

**Укытучы:** Кызлар, барыгыз әле матур гына яңадан кереп күрсәтегез.

*(Ишек шакыйлар)*

***1 кыз:*** Керергә мөмкинме Гөлнара  Закировна?

**Укытучы:** мөмкин укучылар, керегез.Рәхим ит, ....

**2*кыз:*** Рәхмәт, .....Исәнмесез, хәерле көн Гөлнара Закировна!

**Укытучы:** Исәнмесез, рәхмәт укучылар. Утырыгыз.

**Укытучы:** Менә укучылар, ике күренеш. Сезгә кайсы күренеш ошады?

***Укучылар:*** *Икенчесе. Соңга калгач рөхсәт сорадылар. Исәнләшеп керделәр. Бер-берсенә юл бирделәр. Урыннарына дус килеп утырдылар.*

**III. Проблемалы ситуацияне чишү**

**Укытучы:**Димәк, укучылар, бүгенге дәрестә сүз нәрсә турында барачак инде? *(Дуслык турында)*

**Укытучы:**Дөрес укучылар безнең әңгәмәбез, нәкъ шушы дуслык, бердәмлек турында барачак. Дуслык безгә укырга, эшләргә, яшәргә ярдәм итә. Ул безне әйбәтрәк, яхшырак, көчлерәк итә. Кешегә дусларсыз яшәү мөмкин түгел. Дустың булу – зур байлык. Кайвакыт шундый очраклар да була. Я ручка, я дәфтәр өйдә онытылып кала.Бу очракта сез нишлисез?

***Укучылар:****Иптәшләребездән сорап торабыз.*

IV. Өй эшен кабатлау

**Укытучы:** Өйдә нинди әсәрне укыдыгыз?

***Укучылар:***...

**Укытучы:** Бу әкиятне кем язган?

***Укучылар:***...

**Укытучы:** А.Алиш кем ул?

***Укучылар:***...

**Укытучы:** Аның батырлыгы турында ниләр әйтә аласыз?

***Укучылар:***...

**Укытучы:** А. Алишның нинди әкиятләрен беләсез?

***Укучылар:***...

**Укытучы:** Әйе, балалар, Алиш сезне бик яраткан, сезнең өчен бик күп кызыклы әкиятләр иҗат иткән. Алар мавыктыргыч, тирән мәгънәле, җыйнак, музыкаль яңгырашлы. А. Алишны балаларның сөекле язучысы дәрәҗәсенә күтәргән жанр – әкиятләр. Әдипнең "Капкорсак патша” исемле беренче әкияте “Пионер каләме” журналының 1934 елгы 2нче санында басылып чыга һәм нәни укучылар тарафыннан хуплап каршы алына. Шуннан соңгы елларда (1935 – 1940) А. Алиш ике дистәдән артык әкият иҗат итә. Алиш еш кына мәктәпләрдә була, балаларга үзенең кызыклы әкиятләрен укый. Ул балаларны бик ярата.

**V. Уку мәсьәләсен кую һәм чишү.**

**Укытучы:** Бүген дәрестә “Тукмар һәм Чукмар” әкиятнең эзләнү тикшерү эшен алып барабыз. Төркемнәргә бүленеп эшлибез.

<u>Төркемдә эшләү кагыйдәләрен искә төшерик.</u>

- Һәркем үз фикерен әйтә ала.
- Бәрәү сөйли - калганнар тыңлый.
- Һәрбер җавап төркемдә карала.
- Төркемдә уртак нәтиҗә ясала.
- Төркем вәкиле җавапны яклый, дәлилли.

**Укытучы:** Әкият нәрсә турында?

***Укучылар:*** *Чукмар белән Тукмар турында.*

**Укытучы:** Әкиятнең эчтәлеген искә төшерер өчен 1 конверттан рәсемнәр алыгыз. Аларны дөрес тәртиптә урнаштырыгыз

*(Рәсемнәр буенча әкиятнең эчтәлеген кыскача сөйләү)*

**Укытучы:** Балалар, 2 конверттагы сорауларны алыгыз. Төркемнәрегездә аларга җавап табыгыз.

1. Әби ни өчен әтәчләргә җәза бирде?
2. Ул нинди җәза уйлап тапты?
3. Җәза тәэсир иттеме?
4. Сез әтәчләргә нинди киңәш бирер идегез?

**VI. Мәкальләр белән эш.**

**Укытучы:** Балалар, дуслык, дус була белү яхшы сыйфатларның берсе. Безнең халкыбыз мәкальләрендә дә моны күреп була. Мәкальләрне, юкка гына, халык акылы дип әйтмиләр.

**Укытучы:** 3 конвертта мәкальләр. Алар буталга. Мәкальнеә башы белән азагын тоташтырырга.

| | |
|---|---|
| Йөз сумың булганчы, | йөз дустың булсын. |
| Балык сусыз торалмый, | кеше дуссыз торалмый. |
| Аерылганны аю ашар, | бүленгәнне бүре ашар. |
| Дуслык- | зур байлык |
| Бергә тыгыз, | аерым күңелсез |

**Укытучы:** Шушыларның кайсысы әкияттәге әтәчләргә туры килә?

***Укучылар:***...

**Укытучы:** Әтәчләргә нинди сыйфатлар җитеп бетми? (олылар сүзен тыңлау, бер-береңне хөрмәт итү).

**VII. Рефлекция.**

Балаларга төрле төстәге эшләпәләр бирелә.

1. <u>Ак эшләпә.</u> Геройның яки вакыйганың уңай яклары турында сөйләгез.
2. <u>Кара эшләпә</u>. Вакыйгаларның яки геройларның тискәре яклары турында сөйләгез.
3. <u>Кызыл эшләпә.</u> Сездә нинди хисләр туды?
4. <u>Яшел эшләпә.</u> Әкияттән үзегезгә нинди файда аласыз. Нинди нәтиҗәгә килдегез.

**VIII. Белемнәрне бәяләү.**

**IX. Өйгә эш бирү.**

1.Әкиятнең үзегезгә ошаган урынын рәсемгә төшерә аласыз.

**Укытучы:** Син кеше белән нинди дә булса файда өчен түгел, ә ул кеше сиңа якын булган өчен дуслашасың. Аның кызыксынулары, карашлары, эчке дөньясы якын булган өчен. Балалар, бу дәрестән соң бары тик матурлыкка, яхшылыкка өндәүче мультфильмнар гына карарсыз дигән теләктә калам.

***Сабитова Гөлназ Ринат кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль гимназиясе*
*туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Предмет:** Татар теле дәресе, 7нче сыйныф

**Тема:** «Хәл фигыльнең темасын өйрәнүдә интерактив-уен технологияләре куллану».

**Максат:** Укучыларга беренче төр хәл фигыль, аның төркемчәләре турында гомуми төшенчә бирү.

| | | |
|---|---|---|
| **Көтелгән нәтиҗә** | Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре: | укытучы укыганны һәм сөйләгәнне игътибар белән тыңлый белә. |
| | Регулятив универсаль уку гамәлләре: | күнегүләрне бирелгән кагыйдә буенча планлаштыра ала,тикшерә,башкара. |
| | Танып-белү универсаль уку гамәлләре: | ничек?кайчан?нишләгәч?нишләгәнче? соравына җавап булган сүзләрне аера һәм таный,беренче төр һәл фигыль дип аңлый, текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирә. |

| | | |
|---|---|---|
| | Коммуникатив универсаль уку гамәлләре: | уртак эшчәнлек барышында үз фикерен формалаштыра белә, аны башкаларның фикерләре белән чагыштыра, дәлилли белә;<br>оппонентка үз фикерен тыныч, ачык итеп әйтә, дәлилли белә;<br>төрле коммуникатив максатлардан чыгып, телдәге чараларны дөрес куллана, телдән һәм язма сөйләм күнекмәләренә ия була, контексттан чыгып, монолог төзи;<br>төркемдә эшли белә, хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре урнаштыра, продуктив хезмәткә омтыла, төркемдәге эшкә яшьтәшләрен җәлеп итә, яшьтәшләре белән нәтиҗәле, продуктив эшчәнлек оештыра. |
| **Төп төшенчәләр:** | Фигыль, 1нче төр хәл фигыль. | |
| **Фәнара бәйләнеш:** | Татар әдәбияты, рәсем, музыка. | |
| **Чыганаклар** | Татар теле. 7 нче сыйныф: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Р.К.Сәгъдиева, Г.Ф.Харисова, Л.К.Сабирҗанова – Казан: “Мәгариф- Вакыт” нәшрияты, 2022. | |
| **Җиһазлау** | Тач-панель, баян, “Беренче төр хәл фигыль” темасына презентация,карталар, клейлар, тәңкәләр,рәсемнәр, музыка. | |
| **Эшне оештыру** | фронталь,индивидуаль,төркемнәрдә. | |

**Дәрес барышы**

**1.Оештыру этабы**

**Мотивация (Уңай халәт тудыру)**

**Укытучы:** Хәерле көн, исәнмесез,укучылар. Ничек хәлләрегез?

***Укучылар:*** *Ал да гөл хәй,ал да гөл хәй,монда рәхәт ,шуны бел хәй.*

**Укытучы:** Бик яхшы. Туган тел дәресен башлыйбыз. Укучылар, безнең бүген гади дәрес түгел, бездә кунаклар да бар.Алар белән дә исәнләшик әле. *(Исәнләшәләр.)*

**2 этап. Актуальләштерү.Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру.**

**Укытучы:** Укучылар,экранга карыйк әле. (Укучы “Вәхшәт” шигырен сөйли.)

**Укытучы:** Без сезнең белән әдәбият дәресендә М.Җәлил турында сөйләшкән идек. Экранда без аның нинди шигырен тыңлап үттек?

***Укучылар:*** *Вәхшәт.*

**Укытучы:** Укучылар,бу шигырьдә сез нинди фигыльләр күрәсез? *аның нинди шигырен тыңлап үттек?*

*Укучылар (Барлык фигыльләрне әйтәләр).*

**Укытучы:** Бик дөрес,укучылар.Әйдәгез,*жыйнап, карап, көлеп*дигән фигыльләргә игътибар итик әле. Укучылар,әйдәгез бу сүзләрнең тамырын билгелик. *(Телдән сүзләрнең тамырын билгелиләр.)*

**Укытучы:** Яхшы. Укучылар, -ып,-еп,-п кушымчалары хәл фигыльнең беренче төр кушымчалары. Кагыйдәне онытмас өчен картага ябыштырып куегыз.

**3 этап. Уку мәсьәләсен кую.**

**Укытучы:** Кем әйтә, дәресебезнең темасы нинди икән?

**Укытучы:** Дөрес, дәресебезнең темасы “Хәл фигыль». Дәфтәрләрегезне ачыгыз, бүгенге числоны язып куегыз.

**Укытучы:** Укучылар, сез монда нинди гадәти булмаган әйбер күрәсез?

***Укучылар:*** *Баян.*

**Укытучы:** Димәк,без сезнең белән бүген җырлар шәһәренә кунакка барабыз. Ләкин поездга билет алу өчен безгә акча кирәк. Укучылар, сез беләсез инде, җиңел акчалар булмый. Акчаны ничек табарга кирәк?

***Укучылар:*** *Эшләп табарга кирәк.*

***Укучылар:*** *Баян.*

**Укытучы:** Бик дөрес.

**4 этап.Танып белү эшчәнлеге.Уку мәсьәләсен чишү.**

**Укытучы:** Сезнең өстәлләрегездә карта бар. Андагы биремнәрне башкарырга кирәк булачак.

**Укытучы:** Укучылар, сезгә нинди бирем бирелгән, кайсыгыз укып күрсәтә? *(укыйлар)*

**Укытучы:** Биремне аңладыгызмы?

***Укучылар:*** *Әйе.*

*(Картада 3 җырның тексты)*

**Укытучы:** Димәк, сез әзер. 1 минут вакыт бирәм.

**Укытучы:** Укучылар, вакыт чыкты. Әйдәгез тикшерәбез. Чират буенча беренче төркем җавап бирә.

*-1нче төркем җавабы.*

*-2нче төркем җавабы.*

*-3нче төркем җавабы.*

***Динамик пауза.***

**Укытучы:** Укучылар, димәк без инде әзер, сез биремне яхшы итеп үтәдегез. Әйдәгез торып басабыз.

Поездта без ничек барырбыз икән? (укучылар хәрәкәт белән күрсәтәләр)

Бәлки, уң якка ятып барырбыз.

Бәлки,сул якка ятып барырбыз.

Бәлки,кул чабып барырбыз.

Бәлки,тыпырдап барырбыз.

Бәлки,без тыңлап барырбыз.

Бәлки,күзәтеп барырбыз.

Бәлки,чүгәләп барырбыз.

Бәлки,утырып барырбыз.

Без сезнең белән поездта. Урыннарыбызга матур итеп утырабыз.

**Укытучы:** Укучылар, җыр сүзләрегез алдыгызда,төркемнәребез белән күңелсез булмасын өчен җырлап барабыз.

*1нче(2,3) төркем җырлый.*

**Укытучы:** Укучылар,без җырлар шәһәренә килеп җиттек.

*(Экранда музыкаль шәһәр фотосы)*

**Укытучы:** Ә сез җырлар яратасызмы?

***Укучылар:*** *Әйе,бик.*

***5. Яңа белемнәрне ныгыту.***

**Укытучы:** Укучылар, җыр кешене елаткан да,юаткан да. Һәр беребезнең матур яшисе килә. Җыр сүзләре язган кешеләр бик талантлы.Хәзерге заманда алар бик популяр. Әйдәгез без дә үзебезнең талантларыбызны тикшереп карыйк әле.

**Укытучы:** Укучылар,без сезнең белән җырлар шәһәренә юкка гына килмәдек. Монда серле мәгарә бар. Ул елга бер генә ачыла. Без монда үзебезгә бик күп белемнәр ала һәм талантларыбызны ача алабыз. Мәгарәгә керер өчен биремне үтик әле.

Бу сүзләргә рифмалы сүзләр табарга кирәк. Кул күтәреп җавап бирәбез.

***6. Уку эшчәнлеген йомгаклау.***

**Укытучы:** Укучылар,сүзләргә нинди кушымчалар ялганган?

***Укучылар:****ып,еп,п.*

**Укытучы:** Димәк,калын авазлы сүзгә нинди кушымча ялгана?

***Укучылар:*** *-ып.*

**Укытучы:** Нечкә авазлы сүзгә?

***Укучылар:*** *-еп*

**Укытучы:** Сүз тартыкка бетсә,нинди кушымчалар ялгана?

***Укучылар:****-ып/-еп.*

**Укытучы:** Сүз сузыкка бетсә?

***Укучылар:****-п*

**Укытучы:** Укучылар, рәхмәт, һәрберегез дә актив эшләдегез, мин сезгә бүген дәрескә бишле билгесе куям. Иң актив укучыларны билгеләп үтик әле. Кайсыгызда иң күп тәңкәләр?

**Укытучы:** Әфәрин,укучылар. Мәгарәдә белемнәребезне ныгыту өчен менә мондый шигырьләр, җырлар дәфтәре булдыра аласыз (укытучы үзенең җырлар дәфтәрен күрсәтә).

**Укытучы:** Мин дә сезнең кебек мәктәптә укыганда, мәгарәдә булган идем.Минем дә аннан калган серле дәфтәрем бар,монда җырлар,шигырьләр тупланган.

**7. Өй эше.**

1) Серле дәфтәр башлау.
2) 140нчы күнегү,65нче бит.
3) Җыр язап карау.

- Укучылар, бик зур рәхмәт, дәрес тәмам, сау булыгыз.

***Колмөхәммәтова Зөлфия Эдуард кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама»*
*полилингваль гимназиясе башлангыч сыйныф укытучысы*



**Предмет:** Математика, 3 сыйныф.

**Тема:** «Тигезләмәләр чишү (Гади тигезләмәләр чишүнең укучыларда математик сөйләмне устерүдәге әһәмияте)».

**Максат:** Белем бирү максаты:билгесез тапкырлаучы, билгесез бүлүче, билгесез бүленүчеле тигезләмәләр чишү күнекмәләре формалаштыру.

Үстерү максаты: бер билгесезле тигезләмәләр чишү, мәсьәлә чишү күнекмәләрен камилләштерү; функциональ белемнәрне, математик сөйләмне үстерү, математик терминнарны сөйләмдә ныгыту.

Тәрбияви максат: коллективта бер-береңә ярдәмчеллек, ихтирам, дуслык хисләре тәрбияләү.

| | | |
|---|---|---|
| **Көтелгән нәтиҗә:** | Шәхси нәтиҗәләр: | математика фәнен татар телендә өйрәнүгә кызыксыну уяту, укучыларның иҗади сәләтләренең ачылышларына этәргеч ясау |
| | Метапредмет нәтиҗәләре Регулятив УУГ | әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аның белән аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру |
| | Танып-белү УУГ | логик фикер йөртү, сөйләм телен үстерү; математик монологик сөйләмне баету |
| | Коммуникатив УУГ | үз эшен контрольдә тоту, иптәшләренә ярдәм итү. |
| | Предмет нәтиҗәләре | математик темага караган татарча лексиканы дөрес әйтергә һәм сөйләмдә урынлы кулланырга күнектерү. |
| **Җиһазлау** | дәреслек Моро М.И. һ.б. “Математика. 3 нче сыйныф”, 2 нче кисәк. - М: “Просвещение”, 2022. -20 нче бит; Ситникова Т.Н., Яценко И.Ф. Поурочные разработки по математике. Пособие для учителя.-М: “ВАКО”,2021.-274-277 б.б., электрон такта, мультимедиа презентациясе, төркем саен маршрут кәгазе, менеджмет, төркем номерлары | |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, парларда, төркемнәрдә | |

**Дәрес барышы**

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге |
|---|---|---|
| **Уңай психологик халәт булдыру 2 мин** | **Сәламләү.2 мин**<br>Хәерле иртә укучылар. Бүген сыйныфта кем кизү (кем дежур)?<br>Рәхмәт, ... .<br>**Укучылар, кәефләрегез ничек соң?**<br>**Булдырдыгыз, укучылар. Мин бик шатмын!** Шушы күңелле нотада дәресебезне дәвам итик.<br>Бүгенге дәрестә Сез төркемнәрдә эшләрсез.<br>Төркемдә эш уңышлы булсын өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?<br>*Җаваплар тыңлангач, нәтиҗә ясый.*<br>*Димәк, укучылар, Сез барыгыз да төркемдә эшли беләсез. Дәресебез барыбыз өчен дә нәтиҗәле булыр дип өметләнәм.*<br>Һәр укучының төркемдә үз номеры бар. | **Кизү укучы җавабы тыңлана.**<br>Бүген сыйныфта мин кизү. Бүген 28 нче февраль, сишәмбе. Без математика дәресенә әзерләндек. Сыйныфта барыбыз да бар.<br>-Шәп, шәп, шәп!<br>Ал да гөл, һәй,<br>Ал да гөл, һәй!<br>Монда рәхәт,<br>Шуны бел, һәй! |

| | | |
|---|---|---|
| | Вазифаларыбыз да номерлар буенча бүленгән.<br>1 нче номерлы укучылар, кулларыгызны күтәрегез әле. Бүген Сез төркемнәрдә маршрут картасын тутыру буенча җаваплы (маршрут карталарын өстәлдән алалар). Дәрестә һәр эшчәнлек төреннән соң, Сез төркем катнашучыларының әлеге эшне дөрес яки хаталы башкаруын картада тамгалап барырсыз. Әлеге карта дәрес ахырында билгеләр куярга ярдәм итәр.<br>4 нче номерлы укучы, төркемдә эш тәмамлангач, кул күтәреп, сигнал бирер. 4 нче номерлы укучылар, басып күренегез әле. Рәхмәт, утырыгыз. | **Көтелгән җавап үрнәге:**<br>эшне киңәшеп башкарырга; авырлыкта калучылар булса,ярдәм итәргә; бер кеше сөйләгәндә, башкаларга игътибар белән тыңларга; үзеңә йөкләнгән эшне намус белән башкарырга һ.б.<br>1 нче санлы укучылар кул күтәрә, маршрут карталарын ала<br><br><br><br><br><br><br>4 нче номерлы укучылар баса, утыра |
| **Белемнәрне актуальләштерү 4-5 мин** | **Дәресебезне телдән исәпләү күнегүләре белән дәвам итик.**<br>Һәр төркемгә 4 мисал әйтелер. 2 нче санлы укучыдан башлап, һәркайсыгыз берәр мисалның җавабын әйтергә тиеш. Игътибар белән тыңлыйбыз, хаталар булса, дусларыбызның җавабын төзәтәбез. 1 нче санлы укучылар, маршрут кәгазьләрен тутырырга онытмагыз. (мисаллар әйтелә, җаваплар тыңлана)<br>-10 саны белән 54 нең суммасы ничәгә тигез?<br>-71 гә 29 ны куш<br>-беренче кушылучы 21, икенчесе-64, сумманы әйт.<br>- 4 кә 43 не кушам<br>-43 не 21 гә арттыр<br>-14 белән 12 нең суммасы ничәгә тигез була?<br>-12 гә 42 не куш<br>-60 белән 23 нен аермасын тап<br>-30 дан 25 не ал<br>-58 не 41 гә кимет<br>- кимүче 68, киметүче 64. Аерманы тап<br>-51 дән 24 не ал<br>-55 не 47 гә кимет<br>**Булдырдыгыз, укучылар, Сез бик дөрес һәм тиз исәпләдегез.** | Укучылар телдән җавап бирә<br>-64<br><br>-100<br>-85<br><br>-47<br>-64<br>-26<br><br>-54<br>-37<br>-5<br>-17<br>-4<br>-27<br>-8 |
| **Дәрес максатын фаразлау. 3 мин** | Сезгә үзем белән кичә булган бер хәлне сөйлим әле. Эштән кайтышлый, гадәттәгечә, мин кибеткә кереп, кичке аш әзерләргә азык-төлек алдым.Вакыт соң булу сәбәпле, әйберләрнең бәяләрен, түләнгән акчаны да яхшылап санап тормадым. Чекта барысы да язылган, кайткач карармын, дип уйладым. Әмма кайтканда, минем чекка ничектер томат согы түгелеп, андагы саннарны бозган иде. Аларны танырлык та түгел. Сез миңа шул саннарны ачыкларга ярдәм итмәссез микән? Укырга мөмкин булган бөтен язуны мин чиста биткә күчердем.<br>**Электрон тактада презентация ачыла.** | |

| № | Название товара/ Товарның атамасы | Количество/ Саны | Цена/ Бәясе | Стоимость/ Тулы бәясе |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Бәрәңге | | * 32 | = 64 |
| 2 | Ипи | 1 | | = 35 |
| 3 | Сөт | 2 | | =86 |
| 4 | Томат согы | | * 40 | =40 |

Мин нәрсәләр сатып алганмын? Аларны нинди берәмлекләрдә үлчиләр? (һәр төркемнән 3 нче номерлы укучы 1 әр азык-төлекне әйтә)
Укучылар, сез дөрес җавап бирдегез, афәрин. Ә хәзер төркемнәрдә югалган саннарны ничек табарга мөмкин булуын киңәшегез. Сезгә аңларга җайлырак булсын өчен, мин аларны түбәндәгечә күчереп яздым (СЛАЙД №2)

Бәрәңге x* 32 = 64
Ипи 1* b = 35
Сөт 2 * c = 86
Томат согы x * 40 = 40

(Җаваплар 4 нче номерлы укучыларның сигналы нигезендә әйтелә башлый)
Афәрин, укучылар, Сез бик дөрес эшләгәнсез. Укучылар, тактадагы тигезлекләрдә, әйдәгез, компонентларның атамаларын әйтеп китик әле. Хәреф астына яшеренгән тапкырлаучыны ничек атарга мөмкин? Без бүген дәрестә нәрсә өйрәнербез икән? Кемдә нинди фикерләр бар?
Ә билгесез компоненты булган тигезлек ничек атала икәнен кем хәтерли?
Тигезләмәне чишү алгоритмын искә төшерик.

Решение уравнения/ Тигезләмәне чишү
96- x =16
x = 96-16
x= 80 корень уравнения/ тигезләмәнең тамыры
проверка решения/чишелешнең дөреслеген тикшерү
96 - 80=16
16 = 16

Дөрес, билгесез саны булган тигезлек дигезләмә дип атала. Әйдәгез, бергәләп, тактадагы тигезләмәләрнең тамырын табыйк.

x + 19 =42
76 – к =40
y – 10 = 30

Ял минуты (электрон экранга презентация куела)

-Бәрәңге, үлчәү берәмлеге кг
-ипи, данә (штука)
-сөт – каплар саны
-томат согы -каплар саны
(төркемнәрдә киңәшәләр)

**Көтелгән җавап үрнәге**: бәрәңгенең авырлыгын (массасын) табу өчен, 64 не 32 гә бүләбез. Җавап 2 гә тигез. Димәк, бәрәңгене 2 кг алгансыз. (64:32=2 (кг)- бәрәңге, 35:1= 35 (сум)- 1 ипи бәясе, 86 :2= 43 (сум)- 1 кап сөт бәясе,40:40 =1 (шт)-кап томат согы)

**Көтелгән җавап үрнәге**: 1 нче тапкырлаучы, 2 нче тапкырлаучы, тапкырчыгыш.
Билгесез тапкырлаучы.

Көтелгән җавап үрнәге: билгесез саны булган тигезлекләр чишәргә өйрәнербез (тигезлекләрдә билгесез тапкырлаучыны табарга өйрәнербез)
**Көтелгән җавап үрнәге**: бер яки берничә саны билгесез булган тигезлек тигезләмә дип атала.
(Теләгән укучы җавап бирә)

Билгесез санны табу- тигезләмәне чишү була. Табылган сан тигезләмәнең тамыры дип атала. Тамырны тапкач, чишелешнең дөреслеген тикшерергә кирәк.

( Һәр төркемнән 3 нче номерлы укучы тактада 1 тигезләмә чишә. Чишелешне аңлата. Аңлату барышында укучы сөйләмендә математик терминнарның дөрес кулланылышы ассызыклана.

Физкультминут (электрон экрандагы презентация нигезендә ясала)

**Проблеманы чишү этабы. 5 мин**

**Дәреслек буенча эш.**
Укучылар, дәреслекнең 20 нче битен ачыйк. Битнең өске ягындагы тигезләмәләрнең чишелешенә игътибар итик. Тигезләмәләрдә кайсы компонентлар билгесез? Алар ничек табылган?
Һәр төркемнән 4 нче санлы укучылар 1әр тигезләмәнең чишелешен аңлата.
Бик дөрес, укучылар.

Дәреслек, 20 нче бит.
(76:x =38- билгесез бүлүчене табу өчен, бүленүчене өлешкә бүләргә кирәк;
X*7 = 84- билгесез тапкырлаучыны табу өчен, тапкырчыгышны билгеле тапкырлаучыга бүләбез;
X:3= 24- билгесез бүленүчене табу өчен, өлешне бүлүчегә тапкырылыйбыз.)
Дәрес башында без, икенче

<table>
<tr>
<td rowspan="2">**Төзәтү һәм нығыту этабы.<br>20 мин**</td>
<td>Дәрес башында без төзәткән чек белән бу тигезләмәләрнең уртаклыгы нәрсәдә?<br>(укытучы укучыларны тыңлаганнан соң, билгесез тапкырлаучы, билгесез бүленүче, билгесез бүлүчене табу буенча тагын бер кат нәтиҗә ясый)</td>
<td>тигезләмәдәге кебек, билгесез тапкырлаучыны таптык.</td>
</tr>
<tr>
<td>1.Дәреслек буенча эш -№1<br>Тигезләмәләрне аңлатып чишәргә, төркемнәрдә дөреслеген тикшерергә.<br><br>2. Укучылар, сатып-алу темасын дәвам итәбез. 4 нче № да бирелгән мәсьәләне ____________укый.<br>(мәсьәлә чишү алгоритмы нигезендә аның шарты, соравы ассызыклана, кыскача язылышы языла.)<br>Төркемнәрдә киңәшләшеп, мәсьәлә чишелә.<br><br>Мәсьәләне дөрес чишүчеләр, төрле ысуллар белән чишүчеләргә хуплау сүзләре әйтелә.<br>-Укучылар, төркемнәрдә маршрут карталарын тутыра бардыгызмы? Тиешле тамгалар куелды микән?<br><br>3. №3- таблицаны тутырырга.<br>Укучылар, игътибар белән карагыз, монда безгә нишләргә кирәк? (укучыларның җаваплары тыңлана, җавап хаталы булса, төзәтелә). Бирем экранга чыгарыла. Төркемнәрдән чиратлап укучылар чыгып эшли. Бирем урыннарда һәм тактада башкарыла.
<table>
<tr><td>a</td><td>17</td><td></td><td>16</td></tr>
<tr><td>b</td><td></td><td>4</td><td></td></tr>
<tr><td>a*b</td><td>51</td><td>68</td><td>96</td></tr>
</table>
<table>
<tr><td>c</td><td>64</td><td></td><td>80</td></tr>
<tr><td>к</td><td></td><td>6</td><td></td></tr>
<tr><td>c*к</td><td>4</td><td>13</td><td>5</td></tr>
</table>
</td>
<td>**Дәреслек, 20 нче бит №1 урыннарда эшләнә, төркемнәрдә дөреслеге тикшерелә.**<br>**Һәр төркемнән 1нче санлы укучы 1 тигезләмәнең чишелеше белән таныштыра**<br>Мәсьәлә укыла. Алгоритм нигезендә укучыларның сөйләме тыңлана. Кыскача язылыш язалар.<br>Төркемнәрдә киңәшләшеп, мәсьәлә чишелә<br>№4
<table>
<tr><td>Количество туристов</td><td colspan="2">Кол-во консервов Всего консервов</td></tr>
<tr><td rowspan="2">19</td><td>По 2 шт мясных ?</td><td rowspan="2">?<br>консервов</td></tr>
<tr><td>По 3 шт овощных ?</td></tr>
</table>
**1 нче ысул: 2*19+3*19=95 (шт)-консерва**<br>**2 нче ысул:(2+3)*19=95 (шт)-консерва**<br>Мәсьәләнең җавабы языла.<br>**3. №3**<br>1 нче таблицада билгесез тапкырлаучыны табарга кирәк. Аның өчен тапкырчыгышны билгеле тапкырлаучыга бүләбез.<br>2 нче таблицада билгесез бүлүчене табу өчен, бүленүчене өлешкә бүләбез.<br>Билгесез бүленүчене табу өчен, өлешне бүлүчегә тапкырлыйбыз.
<table>
<tr><td>a</td><td>17</td><td>***17***</td><td>16</td></tr>
<tr><td>b</td><td>***3***</td><td>4</td><td>***6***</td></tr>
<tr><td>a*b</td><td>51</td><td>68</td><td>96</td></tr>
</table>
<table>
<tr><td>c</td><td>64</td><td>***78***</td><td>80</td></tr>
<tr><td>к</td><td>***16***</td><td>6</td><td>***16***</td></tr>
<tr><td>c*к</td><td>4</td><td>13</td><td>5</td></tr>
</table>
Такта янындагы укучы эшен комментарияли.</td>
</tr>
<tr>
<td>**Рефлексия һәм дәрескә йомгак.<br>5 мин**</td>
<td>Дәрестә аңлашылмаган мәгълүмат калмадымы? Түбәндәге фразаларны дәвам итегез (№2):<br>-билгесез тапкырлаучыны табу өчен,...<br>-билгесез бүлүчене табу өчен, ...<br>-билгесез бүленүчене табу өчен, ...<br>Укучылар, бүгенге дәресебездә сез үзегезне игътибарлы һәм тәрбияле итеп күрсәттегез. Әйдәгез билгеләр куйыйк. (билгеләр электрон нурналда теркәлә. Укучыларга мактау сүзләреәйтелә)<br>Алдагы дәрселәрдә безне математикадан яңа ачышлар көтә. Ә аның өчен өй эшен дәрес итеп, аңлап башкарып килүегез кирәк.</td>
<td>Укучылар җавап бирә<br><br>-тапкырчыгышны билгеле тапкырлаучыга бүләбез;<br>-бүленүчене өлешкә бүләбез;<br>-бүлүчене өлешкә тапкырлыйбыз.<br><br>Маршрут кәгазен тутыручылар билгеләрне әйтә, комментарий бирә.</td>
</tr>
<tr>
<td>**Өй эше.<br>3 мин**</td>
<td>**Хәзер, көндәлекләрне ачып, өй эшен языйк. Өй эше сыйныфта эшләгән**</td>
<td>Өй эшен язалар. 20 нче бит №7,№3 (бөтен укучылар өчен) +№5</td>
</tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| | **эшләргә охшаш. (өй эшенә аңлатма бирелә)** Математика дәресе тәмам. Хушыгыз. | |

***Унверен Эльвина Айрат кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль гимназиясе*
*туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Предмет:** Татар теле, 7 нче сыйныф.

**Тема:**«Инфинитив турында белешмә».

**Максат:** фәнни максат: инфинитив турында укучыларның белемен системалаштыру, фигыль төркемчәләре турындагы белемнәрен ныгыту;

тәрбияви максат: беренчедән, үз теленә сакчыл караштa булуны, икенчедән, башка милләт вәкилләренә карата хөрмәттә булуларын, өченчедән, яхшы укучының сыйфатларын тәрбияләү;

коммуникатив максат: укучыларның сөйләм байлыгын үстерү, төркемнәрдә эшләргә өйрәтү.

| | |
|---|---|
| **Көтелгән нәтиҗә:** | 1) телебезнең матурлыгын, байлыгын тоярга өйрәтү;<br>2) фигыль төркемчәләрен аера белү күнекмәләрен формалаштыру;<br>3) татар һәм төрек телләрендәге исәнләшү сүзләренә чыгыштырма анализ ясау күнекмәләрен булдыру;<br>4) затланышлы һәм затланышсыз фигыль төркемәчәләрен аера белү күнекмәләрен ныгыту. |
| **Җиһазлау** | ноутбук, проектор кебек техник чаралар ярдәмендә презентация күрсәтелде. Слайдлар, буклет һәм дәреслек ярдәмендә биремнәр, күнегүләр эшләнелде. Балаларга индивидуаль фикерләү, эзләү һәм дөрес җавап табу өчен сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителде. |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, парларда, төркемнәрдә |

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

**1. Дәресне оештыру**

–Хәерле көн, укучылар! Hayırlı günler!

–*Хәерле көн, укытучы апа!*

–Кәефләрегез ничек? Мин сезнең белән нинди телдә исәнләштем?

–*Яхшы, рәхмәт. Кыргыз, казах, төрек?*

–Дөрес, төрек. Мин татар теле укытучысы гына түгел, ә төрек теле укытучысы да. Бүген сезнең белән сәяхәткә чыгабыз. Симит һәм чәй, Босфор һәм акчарлаклар иленә очар өчен очкычка рәхим итегез. Без нинди илгә очабыз, укучылар?

–*Төркиягә очабыз!*

–Укучылар, дәрес барышында дөрес җавапларыгыз өчен тиеннәр өләшәчәкмен. Сез очышка әзерме?

–*Әйе, без әзер!*

–Очкычта һәрвакыт саклану чараларын күрергә кирәк. Ә хәзер җайлап утырыгыз һәм игьтибарыгызны экранга юнәлтегез.

*(“Гөрләп кирәк яшәргә” җырының видеосы күрсәтелә, слайдка сүзләре чыгарыла)*

**2. Актуальләштерү**

– Укучылар, әйтегез әле, әлеге җырда нинди фигыль төркемчәләре кулланылган? 5 секунд уйлап карагыз.

– *Хәл фигыль, хикәя фигыль, … .*

– Дөрес, афәрин, укучылар, фикерләрегез белән килешәм. Чираттагы җырыбызга күчәбез. *(Үзем җырлыйм)*

– Ә бу җырның сүзләрендә нинди фигыль төркемчәләре бар, укучылар? 5 секунд уйлап карагыз.

– *Хикәя фигыль, … , хәл фигыль.*

**3. Уку мәсьәләсен кую**

–Әлеге фигыльләр нинди сорауга җавап бирә?

*–Ни эшләргә? ...*

–Рәхмәт, укучылар. Димәк, безнең бүгенге дәресебезнең темасы нәрсә белән бәйле? 5 секунд уйлап карагыз.

*–Әлбәттә фигыль белән!*

–Әйе, укучылар, нәкъ шулай. Әлеге фигыль төркемчәсенең үзенә хас кушымчалар барлыгын җырлар аша өйрәндек. Димәк, әлеге фигыльнең нинди кушымчалары бар? 5 секунд уйлап карагыз.

*–-ырга/-ергә, ... .*

–Укучылар, әйтегез әле, гомумән фигыль нәрсәне белдерә?

*–Эш яки хәрәкәтне... .*

–Бик яхшы, рәхмәт. Балалар, бүгенге темабыз нәрсәгә багышланган?

*–Фигыльгә, инфинитивка, бәлки.*

–Бүгенге темабыз: ИНФИНИТИВ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ. Укучылар, фигыль төркемчәләрен искә төшереп китик.

Фигыльләр 2 зур төркемгә бүленәләр: ЗАТЛАНЫШЛЫ ҺӘМ ЗАТЛАНЫШСЫЗ. Затланышлы фигыльләргә нәрсә керә?

*–Хикәя фигыль, шарт фигыль, боерык фигыль. Затланышсыз фигыльләргә исә – сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль һәм инфинитив керә.*

–Әйдәгез бергәләп кагыйдә төзик, укучылар. Инфинитив турында нәрсә өйрәндек?

*–-ырга/-ергә, -рга/-ргә, -арга/-әргә кушымачалары бар. Ни эшләргә соравына җавап бирә.*

–Димәк, фигыль – эш яки хәрәкәтне белдерә, ә инфинитив – эш яки хәлнең максат яки тиеш булу мәгънәсен белдерә. Инфинитив – затланышсыз фигыль.

**II. <u>Уку мәсьәләсен өлешләп чишү. Дәреслектәге күнегүләрне үтәү</u>**

–Әйе, дөрес, укучылар, без бүген инфинитив темасын үзләштерәчәкбез. Ә хәзер дәреслекләребезне 79 нчы битен ачабыз һәм инфинитивның кагыйдәсе белән якыннан танышабыз.

–Эш яки хәлнең максат яки тиеш булу мәгънәсен белдереп килгән затланышсыз фигыль инфинитив дип атала. Ул нишләргә? нишләмәскә? сорауларына җавап бирә. Дәфтәрләребезне ачыйк.

–Укучылар, ә хәзер 80 нче битне ачабыз һәм 173 нче күнегүне эшлибез. Сорауларыгыз бармы? 1-2 минут уйлап карагыз.

*–Юк, рәхмәт.*

–Укучылар, җавапларыбызны тикшерәбез. 1 нче команда 2 нче номерлы укучы җавап бирә. Димәк, бу сүзнең тамырын һәм нинди кушымча ялгануын әйтергә кирәк.

*–Сана+рга, утыр+ырга, ят+арга.*

*Төркемнәрдә эш (буклет)*

–Әйе, дөрес. Искишехиргә хуш килдегез! Hoş geldiniz!*(музыка вкл).* Һәр илнең үз кагыйдәләре бар. Ихтирамлы булырга кирәк. Өлкәннәр белән исәнләшергә кирәк. Укучылар, без юкка гына Искешәһәргә килмәдек. Минем сезгә тапшырасы әманәтем бар. Моннан йөз еллар элек бу шәһәргә Сөләйман аксакал килгән. Бу Искешәһәрне Төркиядә татарлар башкаласы дип атыйлар. Бүгенге көндә монда 2000 казан татары яши. Бу аксакал кардәшен күрергә килгән һәм үзенең серле сандыгын онытып калдырган. Укучылар, безгә аксакалның әманәтен үтәр өчен бирем үтәргә кирәк. Өстәлләрегездә төрле биремнәр бар, төркемдәшләрегез белән бергәләп эшләгез. Соңыннан серле сандык ачылачак. Сорауларыгыз бармы?

*–Юк.*

**<u>III. Рефлексив бәяләү</u>**

–Укучылар, татар теле төрки телләр дөньясына юл ача. Татар теле – зур мөмкинлек. Шуңа күрә татар телен камил дәрәҗәдә белергә кирәк! Тырышып укырга сүз бирәсезме? Милләткә зур үрнәк булырга сүз бирәсезме?

*–Әйе, әйе, әйе!*

–Укучылар, без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләштек? Нәрсәләр белдегез?

*–Инфинитив турында сөйләштек. Фигыль төркемчәләрен кабатладык.*

–Өстәлләрегездә тиеннәр тора, алар ярдәмендә сез бер-берегезгә билгеләр куя аласыз. 5-4 тиен – 5ле, 3 тиен – 4ле, 2-1 тиен – 3ле.

–... .

**<u>Өй эше</u>**

1. Сылтама аша Телеграм каналына кушылыгыз. Андагы соңгы биремне үтәгез.

2. Төркемдәшләрегез белән буклетлардагы бөтен фигыльләрне инфинитивка үзгәртеп языгыз.
3. Инфинитивлар кулланып, киләчәк буынга хат языгыз.
–Әфәрин, укучылар, барагызга да рәхмәт! Сау булыгыз! Очрашканга кадәр!
–

***Әхмәдиева Гөлназ Илфат кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль гимназиясе*
*башлангыч сыйныф укытучысы*



**Предмет:** Әйләнә-тирә дөнья, 1 сыйныф.
**Тема:** «Күчмә һәм кышлаучы кошлар».
**Максат:** 1) Укучыларны кошлар төрләре,аларның тормышлары таныштыру.
2) Кышкы көн табигатендәге үзгәрешләрне күзәтергә өйрәтү;
3) Укучыларда кошларга карата сак караш,ярдәмчеллек хисләре тәрбияләү

| | | |
|---|---|---|
| **Көтелгән нәтиҗә:** | Шәхси нәтиҗәләр: | уку эшчәнлеге һәм аның мотивлары арасында элемтә урнаштыру |
| | Метапредмет нәтиҗәләре Регулятив УУГ | укытучы белән бергә уку максаты кую; укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; кагыйдәләрне истә тотып гамәлләр кылу |
| | Танып-белү УУГ | логик фикерләүне үстерү гамәлләре башкару (анализ, синтез); тиешле мәгълүматны сайлап алу; төп мәгълүматны аеру |
| | Коммуникатив УУГ | үз фикерләрен төгәл, ачык, аңлаешлы итеп әйтергә өйрәтү |
| | Предмет нәтиҗәләре | кошларның татарча атамаларын дөрес әйтергә һәм сөйләмдә урынлы кулланырга күнектерү. |
| **Җиһазлау** | дәреслек,презентация, кошлар рәсемнәре,проектор, сүзлек дәфтәре, киселгән кош рәсеме өлешләре | |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, парларда, төркемнәрдә | |

**Дәрес барышы:**

**1. <u>Мотивация (оештыру моменты)</u>**

**Укытучы:**Исәнмесез, балалар! Хәлләрегез ничек?
**Балалар:**
Кояшлы иртә кебек.
Татар телен,анам телен,
Өйрәнергә дип килдек!
Мин иртә белән
Өйләргә керәм,
Иптәшләремнең
Хәлләрен беләм.
Исәнмесез, апалар,
Исәнмесез ,абыйлар,
Сезгә дусларым
Иртәнге сәлам!
**Укытучы:**Хәерле көн,кадерле укучылар! Дәресне башлыйбыз!Утырыгыз.
Матур утсен көнегез!
Көләч булсын йөзегез!
Булыйк һәр чак әдәпле,
Отыйк матур гадәтне!
Дөрес,матур утырыйк!
Тырышып җавап бирик.
**Укытучы:**Буген сыйныфта кем дежур?
Укучылар, әйдәгез һава торышы турында Мәрьямгә сораулар бирик.
**Укучы 1:**Бүген көн нинди?

**Мәрьям:**Бүген көн матур.
**Укучы 2:** Кар явамы?
**Мәрьям:** Кар яумый.
**Укучы 3:**Җил исәме?
**Мәрьям:** Җил исми.
**Укучы 4:** Сина көн ошыймы?
**Мәрьям:** Мина көн ошый.
**Укытучы: М**иңа сезнең җавапларыгыз ошый. Балалар, әйдәгез әле җавап биргән укучыларга рәхмәт әйтик. (Хор бн “ШӘП!”)

**2. Актуальләштерү.**

**Укытучы:** Экранга күз салыгыз әле балалар,нәрсәләр бу?
*- Кошлар.*
**Укытучы:** Кошлар - нәрсә ул?
-*Тәннәре каурый белән капланган һәм очарга яраклашкан хайваннар кошлар дип атала.*
(Слайд 2)

**3. Кыенлык урынын, аның сәбәбен билгеләү.**

**Укытучы:** Экрандагы кошларның кайсылары сезгә таныш? (*Чыпчык, күгәрчен, саескан, песнәк, тукран, сыерчык, карлыгач, карга*)
(Слайд 3)
**Укытучы:** Балалар, кайсы кошларны без кыш көне урамда очрата алабыз? (*чыпчык, күгәрчен, карга, песнәк, саескан*)
**Укытучы:** Дөрес,укычылар. Ә нишләп башка кошларны кыш көне очратып булмый?
- *Чөнки башка кошлар,кышны җылы якта үткәрәләр.Алар суыкка яраклашмаганнар.*
Укытучы: Әфәрин,укучылар. Дөрес.
(Слайд 4)

**4. Кыенлыктан чыгу проектын төзү.**

**Укытучы:** Балалар сезнең алдыгызда киселгән кош рәсемнәре бар.Әйдәгез әле шуларны җыеп,дәреснең темасына ачыклык кертик.
(кучмә кошлар рәсеме,кышлаучы кошлар рәсеме)
**Укытучы:** Кышны җылы якта үткәргән кошларны без бер сүз белән нинди кошлар дип әйтә алабыз, балалар?
- *Күчмә кошлар-перелетные птицы.*
**Укытучы:** Салкынга түзем,кышларын бездә үткәрүче кошларны бер сүз белән нәрсә дибез?
- *Кышлаучы кошлар - зимующие птицы.*
**Укытучы:**Димәк, бүген дәрестә нәрсәләр турында сөйләшербез? (*күчмә кошлар һәм кышлаучы колар турында*)

**5. Төзелгән проектны куллану. Яңа белемнәр ачу.**

**Укытучы:** Нинди кошлар булалар?
- *Күчмә һәм кышлаучы кошлар*
(Слайд 5)
**Укытучы:** Нинди күчмә кошлар беләсез?
- *Карлыгыч - ласточка, куке - кукушка, сандугач - соловей, сыерчык - скворец, журавль - торна*
**Укытучы:** Ни өчен кошлар җылы якларга китәләр соң?
**Укытучы:** Алар нәрсәләр белән тукланалар?
- *Бөҗәкләр*
**Укытучы:** Нинди кошлар кышлаучы кошлар дип аталалар?
- *Салкынга яраклашкан, җылы якка очмаучы кошлар. Чыпчык, күгәрчен, саескан, песнәк, тукран, сыерчык, карлыгач, карга* (Слайд 6)
**Укытучы:** Ни өчен кошларга кышын ярдәм итәргә кирәк? Ничек ярдәм итә алабыз?
- *Җимлекләр куярга, кош оялары ясарга*

**6.Физкультминутка. “Очты-очты“ уены.**

**7. Белемне ныгыту.**

Дәфтәрләрдә эш: бирелгән кош рәсеменнәреннән зәңгәр төс белән кышлаучы кошларны тугәрәккә алырга, күчмә кошларны кызыл төс белән билгеләргә.

**8. Рефлексия.**

**Укытучы:** Дәресебезнең максаты нинди иде?

**Укытучы:** Максатыбызга ирештекме?

**Укытучы:** Нәрсә белдек?

**Укытучы:** Балалар алдыгыздагы 1 кош рәсемен алып,артына исемегезне языгыз әле.

Кем теманы аңлады, күчмә кошларны, кышлаучы кошлардан аера алам һәм кош исемнәрен истә калдырдым дип уйлый, шул тактага чыгып кошларны дөрес урынга урнаштыра.

**Укытучы:** Кемгә әле белемнәрен ныгытырга кирәк?

**Укытучы:** Кемгә бүген бик авыр булды, кемгә ярдәм кирәк?

**Укытучы:** Бик тырышып эшләдегез. Рәхмәт!

***Хәбибуллина Гөлшат Идрис кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль гимназиясе*
*башлангыч сыйныф укытучысы*



**Предмет:** Татар теле, 4 сыйныф.

**Тема:** «Серле сандык».

**Максат:** Укучыларны татар халкының көнкүреш һәм гореф – гадәтләре, йолалары, уеннары белән тирәнтен таныштыру, укучыларның зәвыгын үстерү, халкыбызның рухи байлыгына ихтирам, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләү.

| | |
|---|---|
| **Көтелгән нәтиҗә:** | Балаларның татар халык уеннары турында белемнәре киңәйтү;балалар, арасында мөнәсәбәтләр якынайту; балаларда туган як, аның табигатенә, халкына, милли уеннарына каратахөрмәт һәм мәхәббәт хисләрен уяту. |
| **Җиһазлау** | сандык һәм сандык эчендә - чиккән сөлге, калфак, түбәтәй, китап |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, парларда, төркемнәрдә |

**Дәрес барышы**

**Укытучы**: Исәнмесез, укучылар! **Слайд 1.** Бүген нинди матур көн. Шушы матур минутларда бер-беребезгә шат елмаюлар, күтәренке кәефне бүләк итик әле. Менә хәзер бүлмәбез тагын да матурланды, яктырып китте. Менә, дусларым, җыелып та беткәнсез. Дуслар җыелгач бәйрәм була инде. Татарстан Республикасында **2023 елны** Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде **Слайд 2.**

**Укытучы**: Балалар, кем белә, гореф-гадәтләр нәрсә ул?

***Балалар**: Уеннар, милли бәйрәмнәр, җырлар, гаиләдә булган гадәтләр.*

**Укытучы**: Ә безнең иң яраткан, бөтен дөньяга танылган нинди милли бәйрәмебез бар?

***Балалар**: Сабантуй.*

**Укытучы**: Әйе, балалар, дөрес. Анда нинди уеннар уйнала?

***Балалар:** Көрәш, капчык киеп йөгерү, баганага менү, чүлмәк вату.*

**Укытучы:** Димәк, балалар, безнең дәреснең темасы ничек була?

***Балалар:** Татар халык уеннары.*

**Укытучы:** Дөрес! Афәрин!Әйе, һәрбер кеше үз халкының үткәнен, бабайларның ничек көн иткәнен, ниләр белән шөгыльләнгәнен, гореф-гадәтләрен, йолаларын белергә тиеш. Чөнки үткәнен белмәгәннең киләчәге юк - ди халкыбыз. Гасырлардан-гасырга, буыннан-буынга, әби-бабайдан әти-әнигә, әти-әнидән балага үзләренең борынгы бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын югалтмыйча тапшырып килгән, һәм алар, күпмедер дәрәҗәдә үзгәреп, югалып бетә язып, безнең көннәргә дә килеп җиткән.Бүген без сөйгәнхалкыбызның күңел бизәкләре, уеннары, гореф-гадәтләре белән танышырбыз. (Шакыган тавыш ишетелә)

**Укытучы:** Тавышны ишетәсезме, балалар? Кем икән анда? (Сандык күтәреп Мисыр кунагы керә).

**Укытучы:** Балалар, карагыз әле, безгә тагын бер кунак килгән. Син кем?

***Кунак кызы:** пышылдап колакка әйтә.*

**Укытучы:** Ерак Мисырдан килдем ди, кунак кызы. Татарча да белми икән. Безнең дәрестә калып, татар телен өйрәнсен әле. Буш кул белән килмәгән. Бик матур тартма да алып килгән. Балалар, кем белә, нәрсә бу?

***Балалар:*** *Сандык.*

**Укытучы:** Бик тә дөрес. Әйдәгез,сандыкны ачып карыйк, Ачылмый бит. Бәлки сандык турында матур сүзләр әйтсәк, ачылыр. **Слайд 3.**

***Балалар:*** *Матур, серле, бизәкле, агачтан эшләнгән сандык.*

**Укытучы:** Серле сандык, матур сандык,
Кызыктыра безне күптәннән.
Әйдә карыйк ниләр калган икән
Истәлеккә безгә үткәннән.

(Укытучы сандыкны ача, һәм андагы әйберләрне берәм-берәм алып күрсәтә)

**Укытучы:** Менә бу тубәтәй. Балалар, нәрсә соң ул тубәтәй? **Слайд 4**

***Балалар:*** *Түбәтәй – татар халкының милли баш киеме. Аны бик борыннан ук кигәннәр. Түбәтәйне элек гадирәк материаллардан тексәләр, хәзер инде бәрхет түбәтәйләр киң кулланышта. Аның сәйлән, мәрҗән, алтын җепләр белән чиккәннәре күркәмрәк күренә. Бүген дә түбәтәй татар халкының милли баш киеме булып санала, ир –атлар аны урамда да, өйдә дә, мәҗлесләрдә дә бик яратып кияләр.*

**Укытучы:** Дөрес, тубәтәйне малайлар, абыйлар, әтиләр, бабайлар кияләр.
Бу татарның милли баш киеме.
Килешә ул кемнәр кисә дә.
Исеңдә тот, кадерен бел,
Гасыр буйлап килгән ул безгә.

**Укытучы:** Балалар, әйдәгез “**Түбәтәй” уенын** уйнап алыйк.

*(Балалар түгәрәккә басалар, бер-берсенә түбәтәй бирәләр. Көй ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә. Уен шулай дәвам итә. Җәза үтәгән укучыга,* ***милли бизәк*** *бирелә)*

**Укытучы:** Балалар, нәрсә бу? (калфак курсәтә) **Слайд 5**

***Балалар:*** *Калфак .*

**Укытучы:** Бик дөрес. Кем калфак турында сөйләп китә?

***Балалар:*** *Калфак хатын-кызларның бик яраткан баш киеме булган. Кичләрен утырып кызлар серләшә – серләшә матур бизәкләр төшергәннәр. Шушы матур калфакларны алар бәйрәмнәргә, кунакларга барганда киеп барганнар.*

**Укытучы:** Рәхмәт. Әйдәгез балалар, тагын бер уен уйныйбыз “Башы телемдә, ахыры төендә” дип атала ул. **Слайд 6.** Мәкаль әйтеш була бу. Мин башын әйтәм, төен чишүче ахырын таба. (Әби бау алып 6-7 төен төенли, балалар чишәләр).

- Кем эшләми - *шул ашамый.*
- Оста кулда *һөнәр бар.*
- Тырышкан табар – *ташка кадак кагар.*
- Эш сөйгәнне *ил сөйгән.*
- Ана күңеле балада – *бала күңеле далада.*
- Күрше хакы, *тәңре хакы.*
- Бүгенге эшне *иртәгәгә калдырма.*
- Аз сөйлә - *күп тыңла*

Дөрес җаваплар өчен укытучы укучыларга **милли бизәк** бирә.

*(Укытучы сандыгыннан сөлге чыгара. Укучыларга күсәтә.)*

(Бер бала сөлге турында сөйли. **Слайд 7.)**

**Укытучы:** Бу йөзек – әбиемнән калган истәлек. Мин аны бик кадерләп саклыйм. Аулак өйгә җыелгач, әбием шушы йөзек белән “**йөзек салыш”** уйный торган булган. **Слайд 8.**

***Балалар:*** *безгә дә өйрәтегез әле шушы уенны.*

**Укытучы:** Әйдәгез, барыгыз да тезелешеп утырыгыз, учларыгызны тотыгыз. Мин сезгә йөзек салам. Йөзек кемдә икәнне сизсәгез, аңа берәр “җәза” бирәбез (Йөзек сала). Йөзек кемдә, сикереп чык.

**Укытучы:** укучылар сандык төбендә бер китап та бар бит эле. Бу китап ТАТАР ХАЛЫК ФОЛЬКЛОРы дигән китап. **Слайд 9.** Бу китапта бик куп уеннар да бар. Әйдәгез әле мина бер сан әйтегез.

***Балалар: 35***

**Укытучы:** бу биттә **" Капкалы”** уены бар.

*(10 пар җитәкләшеп зур түгәрәк ясап басалар. Парлар җитәклишкән килеш кулларын өскә күтәреп капка ясап торалар. Көй башлануга арадан бер пар үзе теләгән капкага керә, алар урынына баса, әлеге пар икенче капкага бара. Көй туктауга капкага керергә өлгерми калган пар җәза ала.)*

**Укытучы:** Балалар, ә сез татар халкының нинди җырларын беләсез?

***Балалар:*** *Күбәләк, Җомга, Ай, былбылым, Каз канаты, Эх тала, тала, Әпипә.*

**Укытучы:** Балалар, әйдәгез бер җырлап та алыйк инде.

1.Бас, кызым, Эпипэ,
Син басмасан, мин басам.
Синен баскан эзлэренэ
Мин дэ китереп басам.
2. Бас, кызым, Эпипэ,
Син басмасан, мин басам.
Эпипэнен калачларын
Ашап калыйм ичмасам.

**Укытучы:** Афәрин! Бик оста җырлыйсыз. Ә хәзер сез шат һәм моңсу йөзләр ярдәмендә дәрескә бәя бирегез. Димәк, ................

**Йомгаклау:** Бүгенге дәрестә катнашуыгыз өчен барыгызга да бик зур рәхмәт.

***Ганиева Рузилә Фәвәдис кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль гимназиясе*
*башлангыч сыйныф укытучысы*



**Предмет:** Татар теле, 3 сыйныф.

**Тема:** «Алмашлыклар иленә сәяхәт (Зат алмашлыклары)».

**Максат:** 1. Сүз төркемнәре турында белемнәрне ныгыту, кабатлау, системалаштыру, матур язу күнекмәләрен камилләштерү, танып-белү активлыкларын, бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү өстендә эшләү.

2. Укучыларны алмашлык төшенчәсе, белдерелеше белән таныштыру, җөмләдә зат алмашлыкларын таба белергә өйрәтү, сөйләмдә нинди әһәмияткә ия булуын аңлату;

3. Уку хезмәтенә җитди караш, игътибарлылык, пөхтәлек тәрбияләү, туган телгә мөнәсәбәт һәм кызыксыну уяту, матурлыкны тыя һәм аңлый белергә өйрәтү, яхшылык, изгелек эшләү теләге тудыру.

**Җиһазлау:** ребус, компьютер, идеяләр өчен кәрзин

**Метод һәм алымнар:** эзләнү-тикшеренү методы, парлап һәм төркемләп эшләү, индивиаль бирем үтәү, иҗат итү.

**Дәрес барышы.**

**I. <u>Уңай психологик халәт тудыру.</u>**

**Укытучы:**Хәерле көн кадерле кунаклар, укучылар. Хәлләрегез ничек?

**Укучылар:** Ал да гөл, хәй
Ал да гөл,хәй
Монда рәхәт -шуны бел, хәй!

**Укытучы:** Бик яхшы, балалар! Шундый күтәренке кәеф белән мин сезне сәяхәткә чакырам. Кая икәнен беләсегез киләме? Аның өчен менә бу ребусны чишәргә кирәк.


(Алмашлык)

**Укытучы:** Димәк, без “Алмашлык” иленә сәяхәткә чыгабыз. Үзебез белән менә бу кәрҗинне алабыз. Ул “идеяләр кәрҗине” дип атала, сез аны дәрес барышында үз идеяләрегез белән тулыландырырга тиеш.

**<u>2. Белемнәрне актуальләштерү.</u>**

**Укытучы:**Укучылар,алмашлыклар турында сез нәрсә беләсез, языгыз әле.

*А) Индивидуаль эш, 1-2 минут*

*Ә) Төркемнәрдә эш. Укучылар 1-2 минут вакыт эчендә үз тезислары белән уртаклашалар.*

*Б) Сыйныф белән эш. Бу этапта һәр төркем тема буенча үз фикерен җиткерә. Ләкин җаваплар кабатланырга тиеш түгелләр. Һәр җавапны укучы "идеяләр кәрзиненә" яза бара. "Кәрзингә" дәреснең темасына туры килгән барлык идеяләр, фактлар, терминнар һ.б. языла. Ләкин, язылган бер җөмлә дә, фикер дә тәнкыйтьләнми. Бу этапта барлык мәгълүмат җыела. Укытучы ялгыш фикерләрне төзәтми.*

***Үзбәя.***

**Укытучы:** Дәфтәрләрне ачыгыз, бүгенге числоны язып куегыз. ... *февраль Сыйныф эше.*

**3.Уку мәсьәләсен кую**

**Укытучы:**Алмашлык сүзе рус теленә ничек тәрҗемә ителә?

*Укучы: Местоимение*

**Укытучы:**Без рус теле дәресендә нинди алмашлыклар өйрәндек?

*Укучы: Я, ты, он,она, оно, мы, вы, они*

**Укытучы:**Бу алмашлыклар ничек атала?

*Укучы: Личные местоимения*

**Укытучы:** Кеше үзен ничек атый?

*Укучы: мин*

**Укытучы:**Иптәшегезгә кем дип эндәшерсез?

*Укучы: син*

**Укытучы:**Сезнен янга килеп баскан кешене кем диярсез?

*Укучы: ул*

**Укытучы:**Мин һәм син. Икесе бергә кем була?

*Укучы: без*

**Укытучы:**Син һәм ул. Икесе бергә кем була?

*Укучы: сез*

**Укытучы:**Калганнарга кем дип әйтәсез?

*Укучы: алар*

**Укытучы:**Дөрес, укучылар.Мондый алмашлыклар зат алмашлыклары була. Димәк, без сезнең белән бүген нинди алмашлыкларны өйрәнәчәкбез?

*Укучы: Зат алмашлыкларын (Төркемнәр тагын берәр идея язып куя ала)*

***Үзбәя.***

**Укытучы:** Теманы язабыз

**Зат алмашлыклары.**

(*Физкультминутка үткәрелә)*

**4.Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

**Укытучы:** Укучылар, ә хәзер экранда бирелгән җөмләләрне укып чыгыгыз әле.

| | |
|---|---|
| Айнур мәктәптә бик тырышып укый. | Айнур мәктәптә бик тырышып укый. |
| Айнур –3 нчесыйныф укучысы. | Ул – 3нчы сыйныф укучысы. |
| Айнурның дуслары күп. | Аның дуслары күп. |
| Айнурга 10 яшь. | Аңа 10 яшь. |
| Айнурны барысы да ярата. | Аны барысы да ярата. |
| Айнурдан үрнәк алалар. | Аннан(аңардан) үрнәк алалар. |

**Укытучы:**Кайсы тексттагы җөмләләр матуррак яңгырый? Нигә?(Җаваплар)

**Укытучы:**Нәтиҗә ясыйк. Алмашлыкларның төп вазифасы нәрсәдә?(Алмашлык башка сүзләрне алмаштырып килә.)


**Укытучы:**Укучылар, тема буенча нинди фикерләр туды, кәрзингә салып куегыз.

***Үзбәя .***

***5. Модельләштерү.***

**Укытучы:** Укучылар, фикерләрегеә өчен рәхмәт! Аларның дөрес яки ялгыш икәнен без алдагы дәресләрдә ачыкларбыз. Ә хәзер дәрестә алган белемнәрне тәртипкә салыйк, безгә монда кәрзиндәге фикерләр дә ярдәм итәр.

*( Һәр төркемннән бер укучы тактада эшли, алар "Алмашлык" темасы буенча модель төзи. Калган укучылар дәфтәрдә эшли)*




**Укытучы:**Афәрин, укучылар, рәхмәт сезгә! Җавапларыгыз тулы һәм дөрес.

**Укытучы:** Дәфтәрдәге эшләрне дә тикшерегез әле, балалар.

***Үзбәя.***

*(Тикшерелә һәм нәтиҗәләр ясала).*

**6. Рефлексия.**

**Укытучы:**Укучылар, бүгенге дәрестә бик актив эшләдегез. Әйдәгез, күңелле итеп җырлап тәмамлыйк дәресебезне.

Рәхмәт, дуслар, килгән өчен,
Рәхмәт сезгә, туганнар.
Бердәм булыйк, терәк булыйк
Яңгырасын шушы юллар.
Мин, син, без, сез
Бергә бәхетле без.
Мин, син, без, алар
Бергә бәхетле торалар.
Мин, син, без, сез,
Барыбыз да бер тигез
Мин, син, без, алар
Бергә бәхетле торалар.

***Гомуми үзбәя.***

ҮЗБӘЯ

Фамилия, исем ________________________

| | Бик яхшы | Хаталарым булды | Ярдәм кирәк булды |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |

***Булатова Лилия Шамил кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль гимназиясе*
*тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*



**Предмет:**История, 6 класс.

**Тема:**«Правление князя Владимира. Крещение Руси».

**Цель:**Изучение деятельности князя Владимира.

**Планируемые результаты:**

Предметные

1) умение формулировать тему и определять проблему;

2) формирование умения работать с исторической информацией (осуществлять поиск, систематизировать и представлять результат), усвоение новых понятий; умение анализировать исторические процессы и их значение.

Метапредметные

Развитие речи учащихся, умение работать с различной информацией, формирование навыков сотрудничества в ходе групповой работы

Личностные

Формирование интереса к историческим фактам и личностям, развитие любознательности, умение выражать и отстаивать свою позицию

**Основные понятия, изучаемые на уроке:** Крещение, язычество, христианство

**Вид используемых на уроке средств ИКТ:** Touch-панель (интерактивная доска), презентация, компьютер.

**Тип урока:** урок изучения нового материала, урок - повторение

**Ход урока.**

1. **Организационный момент, повторение домашнего задания.**

Приветствие, проверка подготовленности, организация внимания.

Предыдущая тема – «Становление древнерусского государства»

Для проверки домашнего задания необходим раздаточный материал – карточки с именами князей Древней Руси.

Вопросы для проверки:

1. Какой князь снизил влияние хазар на дела Руси, наладил отношения с Византией, создал единое древнерусское государство, объединив Киев и Новгород? По одной из версии погиб в результате укуса змеи, которая выползла из останков его любимого коня. Ответ: *карточка "князь Олег"*
2. Какой князь расширил границы русского государства, успешно отражал набеги кочевников-печенегов, а также совершил ряд походов на Царь-град (Константинополь) и заключил выгодное торговое соглашение с Византией? Был убит в 945 во время полюдья (ежегодного сбора дани) древлянами. Ответ: *карточка "князь Игорь"*
3. Провела ряд мероприятий, который можно считать налоговой реформой: установила размеры податей в пользу Киева, сроки и периодичность их уплаты, а также систему центров торговли и обмена, в которых более упорядоченно происходил сбор дани -погосты Ответ: *карточка "княгиня Ольга"*
4. Вошёл в историю как полководец, прославившийся битвами против Византии и Болгарского царства Был убит печенегами на одном из днепровских порогов. По преданию печенежский хан сделал из его черепа сосуд для вина. Ответ: *карточка "князь Святослав"*.

2. **Постановка цели и задачи урока. Мотивация учебной деятельности.**

Цель урока:Изучение деятельности князя Владимира.

Задачи: 1. Что явилось предпосылками принятия христианства на Руси?

2. Значение принятия христианства для Древней Руси

*Проблемный вопрос:* Какие последствия для Руси имело бы принятие иной религии?

Запишите тему урока в тетрадь.

Прием «До и после». Учащимся предлагается ответить на вопросы до и после объяснения учителем нового материала. Далее сравниваются результаты.

| *Да/Нет* | *Факты* | *Да/Нет* |
|---|---|---|
| | Владимир - князь, который выбрал христианскую веру для Древней Руси | |
| | Благодаря христианской вере укрепились связи с кочевыми народами, которые тоже приняли христианство | |
| | На Русь из Византии в результате принятия христианства распространились иконопись, письменность и строительство каменных храмов | |
| | Людям разрешали сделать выбор – остаться язычниками или принять христианство | |

**3. Актуализация знаний.**

Поиск решения учебной задачи.

Сначала учащиеся определяют способ поиска информации.

- Где мы можем это узнать? (в учебнике, в Интернете).

**4. Первичное усвоение новых знаний.**

Владимир был язычником. Его образ жизни нельзя было назвать праведным. Князь оправдывал свое поведение вероисповеданием. Дальновидный политик вскоре осознал, что язычество становится преградой на пути развития Руси. Он долго думал и советовался с вельможами, прежде чем решился принять христианство.

Он выбрал православие по геополитическим соображениям, у страны появился влиятельный союзник - Византия. Чтобы укрепить связи, князь решил сочетаться законным браком с сестрой константинопольских правителей Анной Византийской. Императоры поставили условие – князь должен принять их веру.

Принятие единой религии для Владимира определялось в первую очередь политическими мотивами, сложной обстановкой не только внутри государства, но и на его окраинах. В то время южные границы Руси беспрестанно подвергались нападению кочевников, которые жгли нивы, разоряли села и осаждали года. В этих условиях Владимир рассчитывал на дружеские и союзнические отношения с Византией, которые могли состояться только после принятия Древнерусским государством христианства.

Далее реализуется способ достижения информации. Ученики делятся на группы (по рядам) и находят информацию на компьютере, в учебнике.

Для решения проблемного вопроса каждой из групп предлагается выбрать одну из религий, представители которых в качестве послов присутствовали на приеме у князя Владимира (ислам, католицизм, иудаизм). Учитель направляет группы, помогает выделить особенности, систематизировать материал. Время регламентируется.

*Например: Как изменилась бы история Древней Руси, если князь Владимир выбрал мусульманскую веру и принял ислам?*

**5. Первичная проверка понимания.**

Защита докладов у доски (1 человек от группы).

**6. Первичное закрепление.**

На интерактивной доске вопросы для закрепления:

1. Какая религия была у древних славян? (язычество)
2. В каком году было крещение Руси? (988 год нашей эры)
3. Какая страна оказала большое влияние на принятие христианства? (Византия)
4. Какие архитектурные сооружения начинают возводить на Руси после принятия христианства? (храмы, соборы, церкви)
5. Какой город первым принял христианскую веру? (Киев).

**7. Информация о домашнем задании**

Параграф 7, вопросы №1-4 на стр.56

***Галиева Резеда Радислав кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль гимназиясе*
*башлангыч сыйныф укытучысы*



**Предмет:** Әйләнә-тирә дөнья, 3 сыйныф.

**Тема:** «Табигать һәм без».

**Максат:** Табигать турында белемнәрне камилләштерү. Яңа сүзләрне сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү. Аралашу, иҗади фикер йөртә белү сәләтен, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Табигатькә сак караш, мәхәббәт тәрбияләү.

| | | |
|---|---|---|
| **Көтелгән нәтиҗәләр:** | Шәхси нәтиҗәләр: | -укуга карата кызыксыну хисе;<br>-үз мөмкинлекләреңне бәяләү;<br>-нәтиҗәләргә үзанализ һәм үзконтроль. |
| | Метапредмет нәтиҗәләре Регулятив УУГ | -кагыйдәләрне,күрсәтмәләрне истә тотып эшләү;<br>-укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;<br>-эшләрне (биремнәрне) таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау; |
| | Танып-белү УУГ | -укытучының сорауларына җавап бирү;<br>-төрле структураларга нигезләнгән мәгълүматлар белән эшли белү. |
| | Коммуникатив УУГ | -тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>-башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;<br>-парларда эшли белү (күршең белән хезмәттәшлек итү). |
| **Бурычлар:** | Балада яңалыкка омтылу, һәрнәрсәне белергә теләү хисен тәрбияләү. Туган як белән горурлану хисләрен уяту. Табигатьтә булганда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен үтәү. | |

| **Җиһазлау:** | Экран, карточкалар, пазл, маскалар, төсле карандашлар. |
|---|---|

**Дәрес барышы.**

*Укучылар төркемнәрдә эшлиләр. Укучылар йөзгә – йөз, җилкәгә-җилкә куеп, бер өстәл артында дүрт укучы утыра.*

**I. Оештыру. Дәресне башлау,исәнләшү.**

- Исәнмесез! Хәерле көн, кадерле кунаклар!  Хәерле көн, укучылар!
- Малайлар һәм кызлар, кәефләр ничек?
- *Шәп! (Сәләт речевкасы!)*
- Утырыгыз! Дәресебезне башлыйбыз.

**II. Актуальләштерү.**

- Укучылар,бүген көн нинди?
- ... *(Бүген көн кояшлы, салкын, аяз, җилсез, ...)*
- Укучылар, мин сезгә бүгенге көндәй күтәренке кәефләр, дәрестә уңышлар телим. Ә бүген без сезнең белән нинди темага сөйләшербез икән?

Теманы ачыклау өчен ак конвертка күз салыйк әле. Укучылар,  конвертларны ачабыз, андагы рәсем кисәкләрен (пазлны) тактага җыябыз.

- Афәрин! Бик яхшы. 2нче төркем. 3нче төркем.
**Методы обучения:**словесный, обучение, наглядный, демонстрация, репродуктивный, командная работа.


**Оборудование:** презентация, листы А4, текстовыделители, маркеры, карандаши, листочки, индивидуальные памятки (приложение 1).

**Технологическая карта мастер-класса**

**Приложение 1**

| № п/п | Этапы, время, | Время (мин.) | Задачи, решаемые на этапе | Содержание этапа | Методы | Средства обучения | Предполагаемый результат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| I. | Организационный момент | 1 | Создание позитивной атмосферы для деятельности | Приветствие. Представление. Проверка готовности к мастер-классу. | Слово преподавателя | Презентация. Слайд 1 | Готовность к работе всех участников мастер-класса |
| II. | Актуализация | 3 | Мотивация слушателей к участию в мастер-классе | Актуальность темы. Постановка цели мастер-класса | Беседа | Презентация. Слайд 2-5 | Сформированы представления о понятии «Интервью», его возможностях. |
| III. | Практическая часть | 14 | Объяснение алгоритма создания макета первой полосы печатного издания | Демонстрация и отработка приемов работы | Практическая работа (деятельность по алгоритму) | Материалы к мастер-классу | Познавательный интерес к теме мастер-класса, передача педагогического опыта на практике. Осознание каждым участником эффективности использования |
| IV. | Рефлексия | 2 | Подведение итогов мастер-класса. | Самооценка деятельности участников мастер-класса. | Беседа | Презентация. Слайд 6-8 | Высказывание собственного мнения участниками мастер-класса по результатам совместной деятельности Удовлетворенность участников от проделанной работы |



***Гобәйдуллина Эльмира Азат кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль гимназиясе*
*башлангыч сыйныф укытучысы*



**Тема: «Тере билгеләр»**

**Максат:** милли традицияләребез нигезендә ятучы кыйммәтле, милли, әхлаклы сыйфатларны саклау.

**Бурычлар:** тере билгеләр аша татар телен өйрәнү; милли мәдәниятыбызга ихтирам һәм мәхәббәт хисе тәрбияләү; эш барышында куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.

**Мастер –классбарышы**

Хәерле көн, хөрмәтле коллегалар! Без – укытучылар, без һәр көн балалар белән, аларны укытабыз, тәрбиялибез, өйрәтәбез, аралашабыз. Эш барышында проблемалы хәлләр дә булгалый. Аларны ничек читләтеп үтәргә соң? Моның өчен безгә балалар белән бер дулкында булып, алар өчен мөһим булган әйберләрне исәпкә алып эшләргә кирәк.

Безнең балалар укырга ничек йөри? Беренче шарт – махсус форма булу. Ә уку әсбапларын ничек йөртергә? Моны һәрбер бала үзенчә хәл итә. Мәктәпкә барганда, урамга чыкканда хәзерге кызлар һәм егетләрне рюкзак белән еш күрәбез. Кемдер рюкзакны ничек бар, шулай йөртә, ә кайберәүләр рюкзакларына төрле билгеләр (значки), брелоклар тагалар. Әйдәгез, билгеләрдә тукталыйк.

Хәзерге дөнья һәр секунд саен яңартыла торган мәгълүмат белән тулы, шуңа күрә кешеләргә максималь мәгънә бирә торган гадиләштерелгән символлар кирәк. Башкача әйткәндә, һәр кеше үз-үзен белдерүнең үзенчәлекле ысулын эзли, балалар, яшьүсмерләр бигрәк тә, һәм иң популяр ысулларның берсе - значокларны киемгә, сумкага яки рюкзакка беркетү. Мондый гади билге йөртүченең характеры, кызыксынулары турында сөйләп бирә ала. Сәяхәтчеләр еш кына мондый максат өчен төрле илләрнең флагларын яки шәһәрләрнең эмблемаларын кулланалар. Кино, мультфильм яки комикс яратучылар рюкзакны тематик образлар белән бизиләр. Еш кына билгеләрне пластиктан ясыйлар, әмма тимердән ясалган вариантларын да очратырга мөмкин. Мондый әйберләр бик кызыклы һәм оригиналь, әмма аларны үзеңә эшләп булмый, махсус җиһазлар кирәк. Ә менә без сезнең белән бүген, махсус җиһазларыбыз булмаса да, пластик, тимердән эшләмәсәк тә, кулдан тере билгеләр (живучие значки) ясыйбыз. Ни өчен алар тере – живучие, чөнки алар безгә озак еллар хезмәт итәчәк. Кулдан эшләнгән билгеләр киемдә яки рюкзакта матур күренәчәк, чөнки алар оригиналь һәм мондый тагын бер билгене очратырга мөмкин булмаячак.

Беренче эш итеп без билгедә күрергә теләгән образны яки рәсемне сайлыйбыз. 2024 нче ел Рәсәйдә гаилә елы дип игълан ителде, без сезнең белән бүгенге семинарда туган телне укытуның актуаль проблемалары турында фикер алышабыз. Шунлыктан билгеләр өчен сайланган рәсемнәр дә шушы темалар белән бәйле.

Рәсемнәрне сайланганнан соң, аларны төсле принтер аша калын кәгазьдә чыгарырга һәм махсус пленканы кулланып ламинатор аша чыгарырга кирәк. Үзебез сайлаган рәсемне кисеп алабыз, пленканы рәсем кырыеннан 1 мм калдырып кисәргә кирәк.

Алдагы эш итеп, фарфор тәлинкә, кул өчен крем һәм кайнар клей чыгара торган пистолет әзерлибез. Тәлинкәнең уртасына крем сөртәбез, крем өстенә клей чыгарабыз. Ул клей, булачак билгенең зурлыгыннан зуррак булырга тиеш. Шул клей өстенә, ул катып киткәнче, булачак билгене куябыз, ике бармак белән басабыз. Клей билгенең кырыеннан чыгарга тиеш. Клейның катканын көтәбез.

Алга таба билгене тәлинкәдән алабыз, коры салфетка белән кремны сөртеп алабыз, аннан соң юеш салфетка белән чистартып бетерәбез. Кайчы белән билге кырыена чыккан, катып киткән клейны кисеп алабыз. Билгенең артына, беркетү өчен кирәк булган, булавканы клей беләнябыштырабыз. Билге әзер!

***Колмөхәммәтова Зөлфия Эдуард кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль гимназиясе*
*башлангыч сыйныф укытучысы*



**Тема:** «Укучыларның проект эшчәнлеге белән җитәкчелек итү»

**Максат:** башлангыч мәктәптә проект эшчәнлегенең асылы һәм аны оештыру тәҗрибәсе белән таныштыру.

**Мастер-классның бурычлары:**

• Мастер-класста катнашучыларның үзара актив хезмәттәшлеге өчен шартлар булдыру;

• Проект эшчәнлеге турында белемнәрне системага салу;

• Проект эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, экологик темага билборд (баннер) макеты ясау;

• Мастер-класс буенча рефлексия

**Җиһазлау:** презентация, гамәли өлеш өчен таратма материал (шәһәрдәге билборд фотолары, кайчы, келәй, фломастерлар, кисмә-таратма материал, А3 кәгазе, ручка, А4 форматында ак битләр, әзер проектны яклау өчен текст-шаблон)

**Үткәрү формасы:** гамәли шөгыль

**Мастер –класс барышы**

- Хәерле көн хөрмәтле коллегалар. Сезне үземнең укытучы остаханәсендә күрүемә бик шатмын. Очрашуыбыз барыбыз өчен дә нәтиҗәле булсын.

Заман һәм җәмгыять чыгарылыш сыйныф укучыларының төрле фәннәрдән билгеле бер белемнәр тупланмасы булу белән бергә, аларның мөстәкыйль белем алырга сәләтле, максат куеп, үз эшчәнлекләрен оештыру күнекмәләре белән коралланган булуын таләп итә. Укучыларга белем-тәрбия бирү барышында, аларны проект эшләренә җәлеп итү бу юнәлештә уңай нәтиҗәләр бирә. Балалар проект эшләрен яратып башкаралар. Проект эшләре укучыларның белем алуда метапредмет нәтиҗәләренен дә чагылышы булып тора.

Мастер-классыбызның темасы “Укучыларның проект эшләре белән җитәкчелек итү”

***Теоретик өлеш.***

Педагогикада ***проектлар методы*** дигәндә, нинди дә булса гамәли яки теоретик белемнәр булдыруга ярдәм итүче алымнар җыелмасы күз алдында тотыла. Димәк, проект ул - куелган проблеманы чишү барышында, гамәли эш нәтиҗәсе- продуктны булдыру аша дидактик максатка ирешү. Башлангыч сыйныфларда проект эшчәнлегенең максатын сез слайдта күрә аласыз.

***СЛАЙД №1. Башлангыч сыйныфларда проект эшчәнлегенең максаты****: - укучыларның гражданлык позициясен ныгыту, аларны шәхес буларак үстерү,*

*Бурычлары:*

*1. Үз-үзеңә карата хөрмәт һәм уңай бәя формалаштыру.*

*2. хезмәттәшлек күнекмәләре булдыру:*

- *әңгәмә алып бару;*
- *төркемнәрдә эшләргә өйрәтү;*
- *ярдәмчеллек булдыру;*

*3. Җәмгыятьтә үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен үзләштерү.*

Проектлар методына төшенү өчен, математик күнегү башкарыйк.

- Бер сан уйлагыз.
- Аңа шундый ук санны кушыгыз.
- Килеп чыккан җавапка 10 ны кушыгыз.
- Җавапны 2 гә бүлегез.
- Уйлаган саныгызны, килеп чыккан җаваптан алыгыз..

*(дөрес чишелгән очракта, җавап бөтен кешедә дә 5кә тигез.)*

Аңлавыгызча, бу мисалның нигезендә билгеле бер алгоритм ята, җавап, проект җитәкчесе буларак, миңа гына билгеле. Сезнең фикерләүне билгеле бер юнәлешкә борып, без бөтенебез дә бер үк җавапка килдек. Проект эшчәнлегендә дә, ахыргы нәтиҗәне белгән хәлдә, укытучы, эш алгоритмын кулланып, укучыларны аларга билгеле булмаган юллар аша дөрес җавапка, дөрес чишелешкә алып бара.

Без бүген, мини-проект башкарып, моңа ышанырбыз.

Проект башкаруның этапларын сез слайдта күрә аласыз.

***СЛАЙД №3***

***1 этап – проблеманы ачыклау, максат кую.***

***2 этап – проектлаштыру, планлаштыру.***

***3 этап – мәгълүмат эзләү***

***4 этап – продукт, проектны башкару***

***5 этап – презентация.***

Эшебезне проблеманы ачыклаудан башлыйк. Сезнен өстәлегездә текст бар. Шул текстны төркемнәрдә укып, андагы проблеманы билгеләргә кирәк. Моның өчен Сезгә 1 минут вакыт бирәм (текст шулай ук слайдта да тәкъдим ителә: “Экология һәм әйләнә-тирә дөньяны саклау буенча сораулар кешелекнең иң өстенлекле сораулары арасында беренчеләрдән.

Бүгенге көндә көнкүреш калдыкларын аерым җыю буенча җирле хакимият җавап бирә. Кайдадаыр бу эш инде җайга салынган, ә кайдадыр әле оештырылып кына килә.

Бу сорауны чишүгә җәмәгатьчелек катнашында комплекслы якын килү кирәк. Һәр кешенең, яшенә, һөнәренә карамыйча, экологик белемен күтәрергә кирәк. Бу- экологик проблемаларны хәл итүдә беренче адым... **«Подружитесь с экологией»: 5 полезных привычек,** ***Светлана Балаян***,https://www.b-soc.ru/pppublikacii/ekologicheskoe-prosveshhenie-s-chego-nachat-i-pochemu-eto-vazhno/).

- Текстта нинди проблема турында суз бара. (Көтелгән җавап үрнәге: кешеләрнең экологик белемен күтәрергә, кешеләрдә уңай экологик гадәтләр формалаштырырга кирәк)

- Әйе, чыннан да шулай. Ә укытучы буларак, җәмәгатьчелектә экологик уңай гадәтләр булдыру өчен, без нишли алабыз? (Җавап вариантлары: макулатура җыю, куллануга яраксыз батареяларны җыю, чүп-чарны сортларга аеру, агач утырту һәм башка экологик акцияләрдә катаншу)

- Сезнең җавап кабул ителде, рәхмәт. Без югарыда саналган эшләрнең һәркайсында актив катнашабыз, әмма бу эшләр дәвамлы түгел. Алар билгеле бер вакыт аралыгында үткәреләләр һәм тагын күпмедер вакытка икенчел планга күчеп торалар.

Хөрмәтле коллегалар, сезгә бәләкәй генә бер сер ачасым килә. Бүген без экологик уңай гадәтләр формалаштыруда реклама алымы белән танышырбыз. Сез рекламаның нинди төрләрен беләсез? (Җаваплар тыңлана: билборд, баннер, аудиореклама, видеореклама, ролик, җәмәгать транспортында реклама, реклама-афиша һ.б.)

- Дөрес. Мине бүген шәһәр урамнарындагы билбордларга урнаштырылган мәгълүмат кызыксындыра.

Хөрмәтле коллегалар, сезнең өстәлләрдә фотолар бар. Әлеге фотоларны уртак билгеләре буенча төркемләргә кирәк. Моның өчен Сезгә 1 минут вакыт бирәм (төркемнәрдә фотолар карала).

*1 минуттан соң:*

- Вакыт тәмам. Әйдәгез, тикшерик. Фотоларда сез нәрсәгә игътибар иттегез?

- Фотоларда безнең шәһәребездәге баннерлар һәм билбордлар.

- Дөрес. Алардагы мәгълүмат- бүгенге көндә кешеләрнең игътибарын җәлеп итүче иң көчле реклама.

- Фотодагы баннерларны тематик яктан берләштереп буламы?

- (көтелгән җавап): Әйе, аларны сәүдә, Президент сайлаулары, Ватанны саклау, эш урыны, вакансия дигән төркемнәргә бүлеп була.

- Моңа кадәр билбордларга урнаштырылган мәгълүматның тематик төрлелегенә әһәмият биргәнегез бар идеме? (җавап тыңлана)

- Баннерларда, билбордларда, сезнеңчә, нинди мәгълүмат урын алырга тиеш? (көтелгән җавап үрнәге: Безнең шәһәр һәм анда яшәүчеләр өчен әһәмиятле булган, ниндидер проблеманы хәл итүгә юнәлтелгән мәгълүмат урын алырга тиеш.)

- Мин Сезнең белән тулысынча килешәм. Фотодагы мәгълүматны тематик төркемләү һәм укыган тексттагы проблемага бәйле рәвештә, әйдәгез, гомуми проблеманы билгелик.

- Гомуми проблема: Түбән Кама шәһәрендә экологик темага кагылышлы баннерлар юк.

- Проблеманы ничек хәл итеп була?

- Без экологик баннер макетын ясый алабыз. Ул әзер булгач, аны шәһәр идарәсенә тәкъдим итәргә мөмкин булачак.

- Моның өчен нәрсәләрне белергә кирәк?

- Экологик проблемаларны һәм экологик уңай дип саналырга хаклы гадәтләрне.

- Эйе, дөрес. Без үзебез үти ала торган экологик уңай гадәтләрне рекламалый алабыз.

- Сезнеңчә, баннерда , билбордта нинди мәгълүмат булырга тиеш?

- Көтелгән җавап үрнәге: бары тик унай мәгълүмат, слоган, лозунг, рәсем, факт.

- Бик дөрес, җавабыгыз өчен рәхмәт. Экологик тема булгач, без инде яшел фонга әһәмият бирербез.

Уртак проектыбызның исемен мин "Түбән Кама-уңай экологик гадәтләр шәһәре" дип атар идем. (СЛАЙД №3) Бүгенге көндә укучыларда уңай экологик гадәтләр формалаштыру буенча актив эш алып барыла. Балалар макулатура, пластик шешәләрне, кулланылган батареяларны икенчел эшкәртүгә тапшырырга җыялар. Әмма бу акцияләр дәвамлы түгел. Бик сирәк гаиләләр генә көнкүреш калдыкларын аерым җыярга гадәтләнгән. Әйдәгез, үзебезнең баннер макетларында шәһәрдәшләрне уңай экологик гадәтләргә чакырыйк, аларга үрнәк күрсәтик.

Өстәлләрдәге конвертларда макет өчен кирәкле материал. Хәзер төркемнәрдә сез билгеле бер экологик гадәткә реклама баннерын иҗат итәсез. Клей, кайчы, төсле карандаш яки фломастерлардан файдаланырга рөхсәт. Проектны башкаргач, аны әле яклыйсы да була, шуңа күрә якларга да әзерләнәбез. (4-5 минут) (төркемнәрдә пластик, макулатура, батарейкаларны җыю, полиэтилен пакетларны күп кулланылышлы сумкаларга алыштыруны рекламалаган банер макетлары җыела.)

***Проектны ясау өчен вакыт бирелә.***

Карагыз әле, нинди матур макетлар барлыкка килде. Сезнең каршыгызда-күмәк хезмәт җимеше. Бу макетны - проектның продуктын булдыруда сезнең һәркайсыгыз үз өлешен кертте. Әйдәгез, сүз сезгә. Эшләнгән эшегезнең өстенлеге нидә? Максатка ирештегезме? Бу макет шәһәрдәшләребезнең игътибарын җәлеп итәрме? (төркемнәр проектларын яклый)

Барыгызга да бик зур рәхмәт. Проект эшчәнлеге, дөрес җитәкчелек иткәндә, укучыларны белем алуда үзләренә максат куярга; танып-белү эшчәнлегендә бурычлар билгеләргә һәм максатны тормышка ашыру өчен, эшне дөрес планлаштырырга өйрәтә. Без ясаган баннерларны шәһәрдәшләр өчен файдалы булыр дип уйлыйсызмы?

***Гыйләҗева Гөлшат Идрис кызы,***
***Константинова Рамилә Фәнис кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама»*
*полилингваль гимназиясе башлангыч сыйныф укытучылары*



**Тема:** «Чәй яны - гаилә»

**Максат:**1) Балаларны халкыбызның борыңгыдын килгән чәй эчү традициясе, аның барлыкка килү тарихы, чәйнең сәламәтлеккә йогынтысы, файдасы белән таныштыру.

2) Өлкәннәргә карата ихтирам тәрбияләү.

3) Укучыларның сөйләм телен, иҗади сәләтләрен үстерү.

**Җиһазлау:** Төрле үлән чәйләре

**Мастер-класс барышы**

**Оештыру моменты:**

Күңелле музыка яңгырый.

1 нче алып баручы: Безнең халык кунакчыл:
"Якты чырай, такта чәй," – дип,
Каршы ала кунакны.

2 нче алып баручы:Хөрмәтле кунаклар, рәхим итегез!

1. Халкыбыз: "Әйтем – сүзнең бизәге, мәкаль – сүзнең җиләге" дигән.

Сезнең өстәлләрдә мәкальләр бар. Сезгә аларның парларын табарга кирәк.

- Бу мәкальләрдә нинди уртак мәгънә бар?( чәй эчү, табын)

- Ә сез татар халкының бик яратып чәй эчкәнен беләсезме соң? Менә шуңа күрә дә без бүген чәй турында сөйләшергә булдык. Чәй эчү күптәннән инде халкыбызның кунак кабул итү традициясенә әйләнгән.

- Хөрмәтле кунаклар, ничек уйлыйсыз чәй Рәсәйгә кайдан, кайчан, ничек килеп кергән? (җаваплар)

- Ә Рәсәйдә чәй 1638 нче елда барлыкка килә. Монголия ханы рус илчесе Василий Старков аша рус патшасына бүләк итеп пакетлар белән чәй җибәрә. Рус патшасына чәй бик ошый. Аны башта дару кебек кенә кулланганнар.

- 19 нчы гасырның уртасына кадәр чәй бары тик Кытайда гына үскән. Аның үстерү серләрен кытайлар яшереп тотканнар.

Соңрак чәй куакларын башка җылы илләрдә дә үстерә башлаганнар. Шуңа күрә чәй бары тик көньякта гына үсә – Кырымда, Кавказда, Урта Азиядә һәм Әзербәйҗанда.

- Без дә бүген сезгә бүләккә чәй төенчекләре җибәрергә булдык. Аны сез үз кулларыгыз белән ясарсыз.

- Ә хәзер игътибар өстәлләрдәге савытларга. Бу чәйләр турында нәрсә әйтә аласыз? Аларны берләштерә һәм аера торган нинди сыйфатлар күрәсез?

- Кара, яшел, вак яфраклы, уртача яфраклы, эре яфраклы чәйләр бар. Тагын сары һәм кызыл чәйләр дә була. Бу төрле төстәге чәйләр барысы да бер үк чәй куагыннан алына, ә төсләре исә чәй яфрагын эшкәртү ысулыннан тора. Чәйнең тәме һәм исе дә шул ук эшкәртү ысулына бәйле. Төсе буенча яшел, кара, сары, кызыл була. Структурасы буенча: бөртекле, яфраклы, такта чәй була.

- Хөрмәтле кунаклар, чәй файдалы эчемлекме? Файдасы нидә? (җаваплар)

Чәйнең файдасы санап бетергесез.. Чәй - эчәсе килүне баса, кешегә көч кертә, баш мие эшен яхшырта, кеше организмыннан агулы матдәләрне, токсиннарны чыгара, файдалыларын тоткарлый, талчыгуны бетерә. Халкыбыз гомер-гомергә чәйне яратып кулланган. Эчәсе килсә дә, ашыйсы килсә дә, арыса-талса да, кәефе кырылса да, сөенеч-шатлыклары ташып торса да халкыбыз шушы могҗизалы эчемлеккә мөрәҗәгать иткән.

**Чәй төенчекләре ясау.**

Татар халкы чәйләр тагын да тәмлерәк, файдалырак, хуш ислерәк булсын өчен төрле үләннәр салган. Ул мәтрүшкә, бөтнек, юкә чәчәге һ.б. Без дә сезгә шушы үләннәрне чәегезгә кушарга тәкъдим итәбез. (Өстәлләргә үләннәр чыгарабыз)

Көннәребез аяз булсын!
Илләр тыныч булсын!
Остэллэребез мул булсын!
Чәйләрегез тәмле булсын.

- Төрле халыклар чәйне төрлечә эчә. Англиядә, мәсәлән, чәйне сөт белән эчәргә яраталар. Ә Рәсәйдә еш кына лимон кисәге салып эчәләр. Ә менә бездә кемнең күңеленә ничек хуш килә инде: сөт беләнме, лимон беләнме, төрле җимешләр салып эчсәң дә бик тәмле була. Ләкин иң мөһиме – чәй яңа пешерелгән булырга тиеш. Ул вакытта чәй тәмле дә, файдалы да була. “Яна ясалган чәй бальзамга, ә төнгә калдырылганы еланга тин” ди халык.

Һәр хуҗабикәгә 2,5,6 саннарын истә калдырырга киңәш ителә.

- Ничек уйлыйсыз бу саннар нәрсәне анлата икән?

2минут тонәтелгән чәйдәге кофеин кәефне күтәрә, 5 минут тонәтелгән чәйнең эфир майлары организмны тынычландыра, 6 минут пешкен чәй эчүөчен иң тәмле, хуш исле чәй санала.

**Уен “Әйе-юк”**

1. Озак саклаганда чәй үзенең исен югалта. (Әйе)
2. Чәйне ир-атлар гына җыйган, чөнки бу бик авыр эш. (Юк)
3. Рәсәйдә беренче чәй эчү 370 ел элек булган. (Әйе)
4. Чәй кара төстә генә була. (Юк)
5. Чәйне пластик савытларда сакларга кирәк. ( Юк)
6. Төнәткән чәйне берничә көн эчендә кулланырга мөмкин. (Юк)

Чәй яны-гаиләҗаны дип юкка гына әйтелмәгән.

- Ни өчен татар халкы шулай дигән? Ничек уйлыйсыз?

- Табын янында барлык мәшәкатләр онытылган. Чәй туганнарны, күршеләрне дә дуслаштырган. Бер-береннен хәлен белү, матур әңгәмәләр кору матур бер традициягәәйләнгән.

**Йомгаклау өлеше.**

Юкка гына сөекле шагыйребез Г.Тукай үзенең «Тәүлек шигырендә”

Чәй исләргә төшеп,
Халык эшне ташлыйдыр.
Тәмле-тәмле сөйләшеп
Чәй эчәргә башлыйдыр дип язмган.

- Сез мондый чараны әби-бабайлар, әти-әниләр белән үткәрә аласыз. Бу тәрбияви чара буларак әти-әниләрне, балаларны һәм укытучыны берләштерә.

***Зәйдуллина Энҗе Фаиз кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама»*
*полилингваль гимназиясе туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Әхмәдиева Гөлназ Илфат кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама»*
*полилингваль гимназиясе башлангыч сыйныфукытучысы*



**Тема:** «Шәҗәрә – чал тарихка тәрәзә»

**Максат:**

1. Шәҗәрә турында төшенчә бирү, укучыларның белемнәрен камилләштерү;

2. Ата - бабаларның нәсел тарихларын белү һәм саклауның әһәмиятен аңлату;

3. Укучыларга милли патриотик тәрбия бирү. Үз нәселеңне, туганнарыңны ихтирам итү, татар халкының тарихына кызыксыну уяту, үткәннәргә ихтирам тәрбияләү, шәҗәрәләрен өйрәнү теләген булдыру;

4. Шәҗәрәләр төзергә өйрәтү.

**Җиһазлау:** укучыларның шәҗәрәләре, фотосурәтләр, нәсел агачы ясау өчен кирәкле материаллар, презентация.

**Мастер-класс барышы**

**Энҗе Фаизовна**: Халкыбызда элек-электән якыннарга, кардәш-ыруга хөрмәт, кайгыртучан мөнәсәбәт, туган илгә мәхәббәт яшәгән. Бу сыйфатлар борынгылар тарафыннан югары бәяләнгән:

Илен белмәгән – игелексез,
Халкын белмәгән – холыксыз,
Ә нәселен белмәгән - нәселсез,- дигән тәкъбир безне әхлаклы булырга өнди.

Шулай ук «Җиде буыныңны бел!» **-** дигән гади, ләкин искиткеч нәсыйхәткә халкыбызның тирән тарихы сыйган. Юкка гына балалар шагыйре Шәүкәт Галиев:

«Исәннәрнең кадерен бел, үткәннәрнең каберен бел» - дип язмаган. Үз нәселе белән кызыксынмаган кешене киләчәктә ни көтә, буыннар бәйләнешен, туганлыкны өзгән кешедән ни көтәргә? Гаилә тарихын өйрәнүне һәм белүне мин бик мөһим дип саныйм.

**Гөлназ Илфатовна:** Шәҗәрә - гарәп теленнән кергән сүз. Татарча агач дигән мәгънәне белдерә. Буыннарның өзлексез алмашынып торуын күп ботаклы агачка охшатып, бабаларыбыз нәсел тарихы турындагы истәлекләрне нәсел агачы яки шәҗәрә дип атаганнар. Шәҗәрәләр язма һәм телдән сөйләү рәвешендә буыннан буынга күчә килгәннәр. Гасырлар дәвамында татар шәҗәрәсе күп үзгәрешләр кичергән. Бездә шәҗәрәләрнең аерым нәсел, гаилә тарихына караган төрләре аеруча киң таралган.

Генеалогик чыганаклар үз чиратында 3 төркемгә бүленә:

1. Сөйләм телендәге чыганаклар (риваять – легендалар);
2. Матди, материаль чыганаклар (медальләр, акчалар, тәңкәләр, дини әйберләр, герблар);
3. Язма чыганаклар (рәсми чыганаклар: кануни актлар, төрле таныклыклар, хезмәт кенәгәсе); тарихи чыганаклар – елъязмалар, шәҗәрәләр, язма кенәгәләр; гаилә чыганаклары – истәлекләр, төрле язмалар, шәхси хатлар, васыятьнамәләр.

**Энҗе Фаизовна:** Нәсел агачының 3 төре бар: вертикаль, горизонталь һәм түгәрәк.

**Вертикаль шәҗәрә** – бу төр гадәти санала. Ул вертикаль буенча укыла, 2 тибы булырга мөмкин:

- күтәрелә бару (кечкенә буыннардан бабайларга, ягъни аскы өлештә иң кечкенә буын вәкиле, соңыннан аның әти-әнисе, алга таба әби-бабасы һ.б.)
- түшә бару (бабайлардан кечкенә буыннарга таба, ягъни иң ерак туганнан иң кечкенә буын вәкиленә кадәр).

**Горизонталь шәҗәрә –** бу төр Европада нык популяр. Буыннарның барлык вәкилләре бер сызыкка урнашкан һәм сулдан уңга ата-бабалардан киләчәк буыннарга таба укыла.

**Түгәрәк схема буенча шәҗәрә** – иң яшь төре, инглиз һәм француз шәҗәрәләрендә еш очрый. Үзәктә буыннарның иң яшь вәкиле урнашкан спиральсыман түгәрәк формасында. Киләсе түгәрәкләр киләчәк буыннарны символлаштыра, шуңа күрә үзәктән тышкы чикләргә борып укыла.

Нәсел агачын төзү бик җиңел эш түгел. Чөнки моның өчен бөтен якын һәм ерак туганнарыңны белергә кирәк. Шәҗәрә төзү эшен нидән башларга?

- Эшне иң элек әби-бабайлардан, нәселнең иң өлкән кешеләреннән үз нәселең турында сораштырудан башларга кирәк. Иң кирәкле мәгълүмат: әби-бабайларның исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туган елы, үлгән елы һәм туган урыны.
- Бигрәк тә кешенең туган урынын белү мөһим. Исемнәрен, туган елларын гадәттә беләләр, ә менә туган урыннарын күпчелек белми икән. 100 елга кадәр мәгълүматны район ЗАГС бүлегендә табарга була. Аннан әлеге материаллар Дәүләт архивына күчә.

Гимназиябездә Туган телләр айлыгында шәҗәрәләр төзү буенча бәйге үткәрелгән иде. Сезгә дә берничә укучының эшләрен тәкъдим итәргә булдык.

**Зәйнәп Харисова, 1 г**

**Сәхбетдинов Морат, 5 б**

Мин – Сәхбетдинов Морат Марат улы, 5 нче сыйныфта белем алам. Әтием Марат химия заводында эшли, «Химия ветераны» дигән мактаулы исемгә лаек булды. Әнием Фидания 20 елдан артык балалар бакчасында эшли, ул – логопед. 9 нчы сыйныфта укучы абыем Булат бар.

Гаиләбездә яхшы күңеллелек, өлкәннәргә хөрмәт, үткәннәр белән кызыксыну кебек сыйфатлар беренче урында тора. Шуңа күрә без әтием ягыннан да, әниемнең дә нәсел агачын үзебездә саклыйбыз, аны өйрәнәбез, эзләнү эшләре алып барабыз. Һәр ике яктан да туганнарыбыз якты эз калдырган. Үземнең ике бабам да Фәретдин улы Фоат (Магнитогорск шәһәрендә туган,1953ел) һәм Нурулла улы Әлфәт ( Ул Мамадыш районы Норма авылында туган, 1951ел) Химия заводында эшләп лаеклы ялга чыктылар, алар «НКНХ ветераннары» дигән мактаулы исемне йөртәләр.

Әнием ягыннан бабамның әтисе Заһидулла улы Нурулла (1906 елны туган) Сугыш ветераны. Сугыштан исән – сау кайтып, 1993 елга кадәр яшәгән. Алар карт әби Җиһанша кызы Корбанбикә белән 6 бала үстергәннәр. Ә әби үзе яшь вакытта пич чыгарган. Сугыш вакытында Авыл советыннан йон, май, йомыркаларны район үзәге Мамадышка алып бара торган булган.

Заһидулла бабай – балта остасы булган.

Галиулла бабай – күп итеп кош – кортлар асраган, кошчылык белән шөгыльләнгән.

Фәретдин бабай – изоляцияләүче булып эшләгән.

Сәхбетдин бабай Сугыш вакытында Харьков шәһәрендә вафат була. Башка аның турында мәгълүматлар юк.

Минем үземнең нәсел агачын имән агачыннан ясадым, чөнки бу агач нык, чыдам. Безнең дә нәсел шундый имәндәй булсын. Ә буыннарны алтын җепләр белән берләштердем.

Эш барышында мин түбәндәге нәтиҗәгә килдем: җиде буынга кадәр нәселебезне бик яхшы белергә кирәк, чөнки нәселебездә булган тәрбияле, тырыш, белемле, иманлы шәхесләр безгә үрнәк, горурлык булып тора. Ата – бабаларның истәлегенә тап төшермәскә, шул нәселнең лаеклы буыны булырга, аны өзмичә сакларга, дәвам итәргә кирәк. Нәселебез турында үзебез белгәннәрне сакларга, үзебездән соң киләчәк буыннарга тапшырып калдырырга тиешбез.

**Чулпан һәм Айсылу Шакировалар, 2 г, 5 в сыйныф укучылары.**

**Бабам әйтә, һәрбер нәсел**
**Бер мәгърур агач кебек**
**Якын ул, газиз, кадерле,**
**Атаң, я анаң кебек.**
**Ботаклары бихисап күп**
**Бар туганнарың шулдыр.**
**Шушы нәсел агачында**
**Син ботагыңны булдыр.**

Бу шәҗәрә агачыбыз – безнең әниебез ягыннан. Фамилиясе Шакирова Шакир бабайдан. Бу әни фамилиясен калдырган дигән сүз түгел, ә әтинең дә фамилиясе Шакиров. Димәк, без үзебезне чын мәгънәсендә Шакир бабайның варислары дип әйтә алабыз ( әйтеп чыгалар 8 буынны)

Безнең әбиләребез аш-су әзерләргә бик оста булганнар. Әниебез Гүзәл дә бик оста. Табынга килгәндә безнең өстәлдә һәрвакыт татар халык ашлары. Түребездә чәкчәк. Ни өчен чәкчәк? Чөнки

аның һәр төше – гаилә әгъзасы. Ә инде бал белән беркетелгәч гаилә таркалмый, бергә, нык була. Шуның өчен чәкчәкне без бик яратабыз. Ул безнең гаилә символы.

**Шәҗәрә агачын ясау**.

1. Өстәлләребездә имән агачын ясау өчен кирәкле материаллар. Кәгазь пакетны 2 өлешкә бүләбез һәм ачып тагын ике ягын да 2 өлешкә кисәбез.

2. Төп өлешне бөтереп агачның кәүсәсен ясыйбыз.

3. Кискән өлешләрне бөтереп имәннең ботакларын булдырабыз.

4. Савытка яшел төстәге кәгазьне беркетәбез, ә аның өстенә имәнне ябыштырабыз.

5. Әзер имән чикләвекләренә әби - бабайларны язып, астан - өскә, олы буыннан кечкенә буынга үсү тәртибендә имән агачына беркетәбез.

6. Яшел вак кәгазьләрне матурлык өчен агачыбызның төбенә үлән итеп тутырып куябыз. Шәҗәрә агачыбыз әзер.

Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк. Димәк, шәҗәрәсе билгеле булган, үткәненә ихтирамлы халык – игелекле киләчәккә лаек халык! Агачларыбыз корымасын, мәңге яшел булсын!

Шәҗәрәне бүген барлыйбыз без
Үткәннәрне белү бик кирәк.
Нәселемне, тамырымны белми
Җирдә яшәүләре, ник кирәк.
Шәҗәрәне барлау матур йола,
Нәсел-тамырларны эзлибез.
Югалтмыйча аны саклый алсак
Тарихларда калыр эзебез.
Жыр: Адымнарга семинарга
Килдегез безгә.
Туганлыкны онытмыйча
Яшик гомергә.
Шөкер әле, бу дөньяда
Исән сауларбыз.
Тынычлыкта, тигезлектә
Яшик барчабыз.
Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт! Сау булыгыз!

***Гыйләҗетдинова Миләүшә Тимергазе кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама»*
*полилингваль гимназиясе биология укытучысы*



**Тема:** «Татарча фәнни терминнар өйрәнүдә CLIL методикасын куллану»

**Максат:**Укытучыларның һөнәри үсешенә шартлар булдыру; татарча биологик фәнни терминнар өйрәнүдә CLIL методикасын куллану белән таныштыру.

**Җиһазлау:**

Экран, презентация, әгъзаларның төсле рәсемнәре, аерым карточкаларда татарча һәм русча атамалары, һәр партага 3-әр конверт, әгъза системалары язылган А4 форматындагы кәгазь битләре, һәр кешегә йөрәк төзелеше рәсемнәре, фломастерлар, һәр кеше исәбеннән А4 форматындагы кәгазь битләренең ¼ өлеше, липучкалар.

**Мастер-класс барышы:**

Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар! Сезнең игътибарыгызга биологиядан мастер-класс тәкъдим итәсем килә. Билология безнең гимназияда рус һәм инглиз телләрендә укытыла. Шулай булгач, “Туган телләр буенча семинарга биологияның ни кысылышы бар?“ диярсез. Ләкин мастер-класстан соң фикерегез үзгәрер дип ышанам.

“Кашык” “таба” “сөт”, “ишек”, сабын” “көрәк”... Шушы көнкүреш сүзләрен без бик еш файдаланабыз. Әйбәт. Ә менә “күзәнәк” “җир-су хайваннары” “сөйрәлүчеләр” “матдә” “җисем” “ярымутрау” “күкерт кислотасы” “бакыр сульфаты” “тапкырлыйбыз” “тигезләмә” кебек фәнни сүзләрне соңгы тапкыр кайчан ишеткәнебез бар? Кайчандыр татар авылларында, татар мәктәпләрендә барлык предметларны татар телендә укыган 40-50-60 яшьлек кешеләрнең хәзер

бөерләре авыртмый, “почки”лары авырта, даруларны чамасыз куллану бавырларына зарарлы түгел, “печеньнарына зарарлы”. Әле “зарарлы” булса әйбәт, күп очракта “печеньнарына вредно”. Ә татар балаларының татарча фәнни сүзләрне ишеткәннәре дә юк диярлек. Биология укытучысы буларак, шул ук вакытта татар кешесе буларак, мин телебездән фәнни терминнарның төшеп калуына битараф кала алмыйм. Татар теле көнкүреш теле генә булып калмасын иде, аның фәнни сүзләргә дә хакы бар.

Белүебезчә, хәзер чит телләрне яхшы өйрәнер өчен CLIL (Content and language integrated learning) методикасы яки предмет-тел интеграциясе популярлашып бара. Гади тел белән әйткәндә, укучы тел белән бергә ниндидер уку предметын да өйрәнә. Мәсәлән, математика, география, биология һәм башкалар. Ягъни, балалар нинди дә булса предметны чит телдә өйрәнә. Телләр өйрәнер өчен бу бик нәтиҗәле чара булып тора. Шулай булгач, нигә әле татар телен тирәнрәк өйрәнер өчен дә бу методиканы кулланмаска? Мәсәлән, балалар белән сыйныфтан тыш эштә.

CLIL методикасы буенча дәрес барышында инглизчә 4 “С” гамәлгә ашырылырга тиеш: Content (эчтәлек), Communication (комуникация), Cognition (фикерләү), Culture (культура).

Бу методика ике төргә бүленә: йомшак CLIL һәм каты CLIL. Каты CLILның нигезендә предмет үзе тора, укытучы күбрәк предметны өйрәтүгә игътибар итә. Йомшак CLILның төп максаты – телне өйрәтү, ә предмет җиңеләйтеп бирелә. Мастер-классымда мин йомшак CLIL куллану мисалын күрсәтәсем килә. Моның өчен югарыда әйтеп үтелгән 4 “С”ны да кулланырна тырыштым.

Ә хәзер тикшереп карый әле, сез кеше органнарының татарча ататмаларын яхшы беләсез микән? Шулай ук анатомия буенча да белемнәрегезне тикшереп карыйк. ***Кунаклар 4 төркемгә бүленеп утырган, һәр төркемдә 4әр кеше***. Сезнең өстәлләрегездә 3 конверт. Аларның берсендә кеше органнарының рәсемнәре, икенчесендә русча атамалары, өченчесендә – татарча атамалары. Шулай ук өстәлләрегездә орган системалары язылган кәгазь битләре ята. Органнарның рәсемнәрен, татарча һәм русча атамаларын туры китереп, кирәкле орган системасы язылган кәгазь битләренә урнаштырыгыз. ***Төркемнәрнең төрлесенә төрлеәгүза системалары бирелә.***

Әйдәгез, хәзер тикшереп карыйк: биремне дөрес үтәдегез микән. Экрандагы дөрес җавапларгы күз салыйк:

1. Нерв системасы (баш мие - голвной мозг, арка мие – спинной мозг)
2. Канәйләнеш системасы (йөрәк-сердце, кан тамырлары – кровеносные сосуды)
3. Бүлеп чыгару системасы (бөерләр – почки, сидек куыгы - мочевой пузырь)
4. Сулыш алу системасы (борын куышлыгы – носовая полость, бугаз – гортань, трахея – трахея, үпкәләр – лёгкие)
5. Ашкайнату системасы (авыз куышылгы – ротовая полость, үңәч – пищевод, ашказаны – желудок, эчәклек – кишечник, бавыр – печень, ашказанасты бизе – поджелудочная железа)
6. Терәк-хәрәкәт аппараты (сөякләр – кости, мускуллар – мышцы)
7. Эндокрин системасы (калкансыман биз – щитовидная железа, чәнечкесыман биз – вилочковая железа, бөер өсте бизләре - надпочечники)

Биремне яхшы үтәдегез. Әфарин!

Хәзер, хөрмәтле кунаклар, татарча бер матур җыр тыңлап алыйк әле. ***Салаватның “Су өстендә балык уйный” җыры видеосы күрсәтелә.***

Су өстендә балык уйный
Иртә дими, кич дими.
Ике **йөрәк** бергә тибә
Таң атканны да сизми.

Салават кешенең нинди әгъзасы турында җырлый? Дөрес, йөрәк турында. Димәк, хәзер без йөрәк турында сөйләшәчәкбез.

Безнең йөрәк кайда урнашкан? Әйе, күкрәк куышлыгының нәкъ уратсында ике үпкә арасында. Йөрәкнең русча атамасы да “середина” – “урта” сүзеннән алынган. Ләкин без йөрәк тибешен сул яктан тоябыз, чөнки аорта сул якта урнашкан.

Сезнең өстәлләрегездә һәрберегез алдында йөрөк рәсемнәре ята. Фломастерлар белән мин әйткән йөрәк структураларының атамаларын, уклар ярдәмендә шул рәсемнәргә сызып күрсәтеп барыгыз.

Башта йөрәк катламнарын карап үтик. Йөрәк 3 катламнан тора: тышкы катлам – эпикард, ул тоташтыргыч тукымадан (соединительная ткань) тора. Урта катлам – миокард, ул мускул

тукымасыннан (мышечная ткань) тора, бу – иң калын катлам. Эчке катлам – эндокард, ул эпителиаль тукымадан ясалган. Йөрәк үзе “йөрәк пәрдәсе” дип аталган, тоташтыргыч тукымадан торган капчык эчендә урнашкан. Капчык белән йөрәк арасында сыекча бар. Ничек уйлыйсыз, ул нәрсәгә кирәк? Әйе, ул саклау фунциясен үти, йөрәк типкән вакытта  капчык стенасынатиеп, ышкылып таушалмасын өчен кирәк.

Ә хәзер йөрәкнең эчке төзелешен өйрәник. Кеше йөрәге, барлык Имезүчеләр классы вәкилләренеке кебек, 4 камерадан тора: уң һәм сул йөрәгалды (предсердия), уң һәм сул карынчыклар (желудочки). Уң йөрәгалды һәм уң карынчык арасында, сул йөрәгалды һәм сул карынчык арасында капкачлы клапаннар (створчатые клапаны) урнашкан. Алар кан бер юнәлештә генә – йөрәгалдыннан карынчыкка гына аксын өчен кирәк. Киресенчә – карынчыктан йөрәгалдына кан агарга тиеш түгел.

Капкачлы клапаннардан тыш йөрәктә ярымайсыман (полулунные) клапаннар да бар. Алар канның карынчыклардан артерияләргә чыгу урынында урнашкан. Алар да кан бер юнәлештә генә аксын өчен кирәк. Кан карынчыклардан артерияләргә генә агарга тиеш, киресенчә -артерияләрдән карынчыкларга кан агарга тиеш түгел.

Һәр кешенең йөрөге якынча үзенең йодрыгы зурлыгында. Ләкин төрле факторлар йогынтысында йөрәкнең зурлыгы үзгәрергә мөмкин. Мәсәлән, спортсменнарның йөрәге зуррак, чөнки аларның миокардлары күп эшләү нәтиҗәсендә калыная. Андый йөрәк күчле була, әйбәтрәк эшли. Шулай ук спиртлы эчемлекләр белән мавыгучы кешеләрнең дә йөрәкләре зур. Аларның йөрәгендә миокрад күзәнәкләренең күп кенә өлеше үлеп җимерелә һәм тоташтыргыч тукыма белән алышына. Ул тукыма йөрәкне зурайта. Ләкин тоташтыргыч тукыма кыскара алмый (не способна сокращаться). Шуңа күрә, зур булуга карамастан, мондый йөрәк үз эшен җиренә җиткереп башкара алмый, ул көчсез була. Нәтиҗәләр ясап торуның кирәге юктыр дип уйлыйм.

Ә хәзер, хөрмәтле коллегалар, бер күңелле бирем үтәп алыйк (Куиз-куиз-трейд). Сезнең алларыгызда менә шундый кечкенә кәгазь битләре ята. Ул кәгазьләргә бу дәрескә кагылышлы бер сорау язасыз. Аның җавабы кыска булырга тиеш. Мәсәлән, “йөрәгаллары белән карынчыклар арасында нинди калпаннар урнашкан?” дигән сорау, “капкачлы клапаннар” дигән җавап. Шул җавапны кәгазьнең аскы өлешенә язасыз һәм кешегә күренмәмслек итеп бөкләп куясыз. Барыгыз да әзер булгач үзегезнең өстәлдән булмаган кешеләр белән парлашып басасыз һәм сорауларыгызны бер-берегезгә бирәсез. Башта сорауны кемнең буе озынрак, шул кеше бирә, кыскарак буйлы кеше җавап бирә. Әгәр ул җавапны белмәсә, сорау бирүче үзе җавапны әйтә. Аннары киресенчә. Аннан соң карточкаларыгыз белән алышынасыз һәм үзегезгә икенче пар табасыз. Шулай итеп һәрберегез 4 кеше белән сорау алышып җитешергә тиеш.

Ә хәзер, хөрмәтле кунаклар, уйлап карыйк,  бу дәрес барышында без CLIL методикасының 4 «С» хәрефен ничек итеп гамәлгә ашырдык?

***Экранда түбәндәге таблица күрсәтелә.*** Өстәлләрегездә менә шундый таблицалар белән карточкалар ята. Сул баганада CLIL методикасының 4 “С” лары, уң баганада аларны гамәлгә ашыру мисаллары буталып бирелгән**.** Сезнең бурыч – аларны уклар ярдәмендә дөреслəп туры китерү. Башта төркемнәрдә эшлик, аннары бергәләп тикшерербез.

| **4 «С»** | **Гамәлгә ашыру мисаллары** |
|---|---|
| (Content) Эчтәлек | Куиз-куиз-трейд алымын куллану |
| (Communication) Коммуникация | Спиртлы эчемлекләрнең йөрәккә зыяны турында укытучының сөйләве. |
| (Cognition) Фикерләү | Йөрәк төзелеше турында укытучының аңлатуы |
| (Culture) Культура | Әгъзаларның русча, татарча атамаларын рәсемнәр белән туры китереп ябештерү биреме |

Бу методиканы биология ярдәмендә генә түгел, башка предметлар ярдәмендә дә гамәлгә ашырырга була. CLIL белән предмет укытучысы гына түгел, тел укытучысы да куллана ала, чөнки, күрүегезчә, предмет белеме җиңеләйтеп бирелде. Мастер-классым барыгыз өчен дә файдалы булгандыр дип ышанам. Игътибарыгыз өчен чын йөрәктән рәхмәт! Сәламәт булыгыз! Йөрәгегезне саклагыз!

***Мостафина Айгөл Фаиз кызы,***
*«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль гимназиясе*
*башлангыч сыйныф укытучысы*



**Тема: «Сувенир курчак»**

**Максат:** милли традицияләребез нигезендә ятучы кыйммәтле, милли, әхлаклы сыйфатларны саклау.

**Бурычлар:** милли мәдәниятыбызга ихтирам һәм мәхәббәт хисе тәрбияләү; эш барышында куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.

**Мастер-класс барышы:**

- Хәерле көн! Кәефләрегез ничек?

СЛАЙД 1.

- Бүгенге мастер-класс сезнең өчен кызыклы, файдалы булыр дип ышанып калам.

СЛАЙД 2.

Курчак ясау – борынгы сәнгать. Татар халкы элек-электән рус халкы белән янәшә яшәгән, шунлыктан татар халык уенчыклары рус уенчыклары белән охшаш. Әбиләребез курчакларын чүпрәктән ясаганнар. Татар хатыннары балаларына ясаган курчакларны буыннан-буынга тапшырганнар.

СЛАЙД 3.

Күп кенә гаиләдә курчак җан ярдәмчесе, гаилә бәхетен саклаучысы булган.

Курчакларны ташларга ярамаган, чөнки курчак ясаучы аңа үзенең күнелен биреп ясаган. Шуна да, курчакны сандыкка киләчәк буын өчен салып куйганнар.

Татарлар курчакка исем кушмаганнар. Курчакның йөзе дә булмаган, ул ак булып калган. Йөзе булмаган курчак балага зыян китерә алмаган, чөнки аңа усал көчләр керә алмаган. Ул балага сәламәтлек, шатлык, иминлек китергән дип саналган.

СЛАЙД 4.

Курчак тарихында үзгәрешләр була, аны чүпрәктән генә түгел, балчыктан, җептән, саламнан, сөяктән, агачтан, хәттә эремчектән дә ясыйлар. Курчак үзе барлыкка килми, аны кеше уйлап чыгара һәм ясый. Шуңа күрә алар бик күптөрле.

СЛАЙД 5.

СЛАЙД 6.

**Укучы 1 (Самира):**

Бүген без дә сезнең белән үз кулларыбыз белән агач тактада сувенир курчак бизәп карыйбыз.

**Укучы 2 (Амир):**

Ул татар кызы. Татар хатын-кызларының борынгы күлмәгенә төрле бизәкләр чигелгән. Күлмәкне бик матур итеп теккәннәр.

СЛАЙД 7.

**Укучы 3 (Лейла):**

Лалә чәчәге – татар халкының милли бизәге дә, аның белән калфакларны, түбәтәйләрне, бизиләр.

Әйдәгез эшне башлап җибәрик...

- Балалар, сез безнең кунакларга ярдәм итеп торырсыз.

*Иң беренче нәрсә эшлибез?*

- Баштан вак өлешләрне бизибез.

*Лалә чәчәген нинди төскә буйыбыз?*

- Лалә чәчәген кызыл төскә буйыбыз.

*Күлмәкне ачык төсләргә буйыбыз.*

- Күлмәкне сары, зәңгәр төсләргә буярга була.

Менә курчак әзер. Бүгенге семинарның бер истәлеге булып торсын!

Эшегездә уңышлар. Мастер-класста катнашуыгыз өчен зур рәхмәт!

# ОБРАЗОВАНИЕ
## НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**УЧРЕДИТЕЛЬ**
Управление образования Исполнительного комитета
Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан

**ПРЕДСЕДАТЕЛЬ РЕДАКЦИОННОГО СОВЕТА**
**Рамазанова А.Р.** – заместительначальника управления образования Исполнительного комитета Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан

**ГЛАВНЫЕ РЕДАКТОРЫ**
**Джалолова Р.И. -** директор МБУ «Центр образования» Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан

**РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ**
**Исмагилова Р.Р. -** методист информационно-методического отдела МБУ «Центр образования» Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан
**Мифтахова Э.Ф. -** заместитель директора по учебной работе МБОУ «Лицей №14» Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан
**Исмагилова А.А. -** заместитель директора по учебной работе МБОУ «Полилингвальная гимназия «Адымнар-Нижнекамск» Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан
**Гарипова Л.Р. -** учитель родного (татарского) языка и литературы МБОУ «Каенлинская СОШ» Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан

**АДРЕС РЕДАКЦИИ**
МАУ ДО «Центр технического творчества и профориентации»
423570, РТ, г. Нижнекамск, ул. Ахтубинская, 4.
Тел.: (8555) 30-85-66; E-mail: cttip-nk@yandex.ru

Центр не несет ответственности за содержание полиграфической продукции, а так же за последующую установку, распространение, размещение и иное использование.